


АЗАТ ХАТЫН

1926 ЕЛДА ЧЫГА БАШЛАДЫ

ЯНВАРЬ • 1978





С. ТОКАРЕВ фотоэтюды.

Фәннур САФИН

Карлар ява

Кешеләрне гел аклыкка,
матурлыкка чакырып,
туган якта карлар ява,
ява карлар —
яктырып.

Күңелләрдә пакь теләкләр —
Яңа елның кары күк,
яшь кияүнең ак күлмәкле,
мең өметле яры күк.

Күзләрдән дә гел яктылык
бөркелә, кая барма!
Яңа елның ак бәхете
тирбәлә һаваларда...

Әй, елмая кеше! —
Елы
яңага авыша бит,
сәгать телләре шикелле
җаннар да кавыша бит!..

...Шушы көндә кар төшмәгән
илләргә дә эндәшеп,
туган якта карлар ява
яктырып, җемелдәшеп...

Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!



АЗАТ ХАТЫН 1

ЯНВАРЬ
1978

Иҗтимагый-политик һәм әдәби-нәфис журнал.

© «Азат хатын», 1978 ел.

БӘХЕТ КОШЫ

Ул аермачык ишетте — Дамир җырлый иде моны. Роза күзләрен ачып җибәрде. Җырның дәвамын ишетергә теләп күзен кабат йомды. Ләкин ягымлы моң бүтән ишетелмәде. Бүлмәдә кызлар гына тирән сулап йоклыйлар. Роза будильникка үрелеп карады. Төнге сәгать бер икән. Дамир җырлавын төшендә ишеткән ләбаса ул! Кичтән: «Мин азрак утырам әле, тиреләрдән кыркып алынган йонны бер цехтан икенчесенә күчерү әмәлен табып булмасмы», дигән иде.

«Һаман утыра икән әле», — диде Роза эченнән генә ирен кызганып. Шулай да, «ят инде, тиздән таң ата бит» дияргә ашыкмады, чөнки белә: барыбер тыңламаячак. Бу хакта ул һәр көн саен сүз кузгатмый калмый. Бүген исә әнә төн ката утырырга булган инде, алайса. «Ә мин җыр дип әверәләнәм...» Роза үзен эчтән генә битәрләп алды.

* * *

Дамир туып үскән йорт мех фабрикаларының күршесендә үк. Өйдән чыктыңмы, бистә халкы әйтмешли, меховой коймаларына барып терәләсең. Дамирны исә балачактан ук коймалар эчендәге машиналар кызыктыра. Әтисенә ияреп меховойга «эшкә» баргач, ул аларны хәтта үз куллары белән тотып карау бәхетенә ирешә.

— Әнисе, малай машиналар тирәсендә кайнашырга ярата, рәт чыгар төсле үзеннән,— ди Габделкаюм абый Рокыя апага.— Мин аны ешрак алып килгәләрмен әле.

1953 елның көзе. Әти-әниләре эзеннән меховойда эшләүче апалары Рәйхана, Зөлхәбирә, Сәлимә, Әминә артыннан беренче мех фабрикасына инструментчы-слесарь һөнәрен өйрәнергә Дамир да эшкә китә. Балачактан якын булган хезмәте турында хәзер Дамир горурлык белән болай ди:

— Артельләр берләшкәч, әнием үлгәннән соң әтиемнең гомер юлдашы булган Рокыя апа да берләшмәгә эшкә күчте. Без бер йорттан меховойга өчәүләп чыгып китә идек. Алар пенсиягә киткәнче мех эшенә тугрылыклы булып калдылар. Бервакыт шулай, барыбызның меховойда эшләгән эш елларын кушып караган идем, ике йөз елга якынлашып килә. Мин киткәнче ике йөз дә булыр. Кызларым династияне дәвам итсәләр, артып та китәр, дип уйлыйм.

— Дамир үз ягын гына санап, әзрәк хәрәмләшә, мин үзем дә мехчы кызы, әниемнең сеңелесе Нәсимә апа да минем белән бер цехта, баш киемнәренең сыйфатын тикшерә,— ди Роза.

Розаның мех кисүче һөнәрен үзләштерүгә әнисе Һадия апаның да, Нәсимә апаның да йогынтылары зур була.

Роза беренче фабрикада беренчеләрдән булып «Коммунистик хезмәт ударнигы» исемен алган әнисе белән горурланып үсә. Әнисе аңа кичләрен үзе эшли торган бизәү цехы коллективы турында сөйли. Бүген товар әйбәт килде, норманы арттырып үтәдек, дигән көннәре еш була. Мең төрле мәшәкатьләре белән Розаның күз алдына фабрика тормышы килеп баса.

Урта мәктәпне тәмамлагач та:

— Мех кисүче булам, комбинатның өйрәнчекләр мәктәбенә йөрим, — ди ул әнисенә. Мәктәптә әйбәт билгеләргә укыган кызның мондый карарга тиз килүе сәеррәк тоелса да, әни кеше каршы килмәде.

— Эшең — тормыш көзгең, бәләкәй генә хаталар да анда ялтырап тора, — ди Һадия апа кызына.

Уку еллары тиз үтә. Роза иртәгә фабрикага эшкә барасы дигән төндә рәтләп йоклый да алмый. Күңел сизенгән булган икән. Беренче көнне үк деталь кисәргә 145 квадрат дециметр мехы җитми кала...

Аннан бирле инде унҗиде ел гомер узган. Розаның исә ул көнне елавы әле дә хәтерендә.

— Безнең эштә мех кисүченең осталыгын билгели торган төп нәрсә — мехны тигез куллану... Күзләремә тулган яшьне күрү белән остазым Нина апа ярдәмгә килеп җитә иде. Без аның белән бүген дә дуслар,— ди Роза фабриканың алдынгы эшчесе Нина Шашурина турында.

Һадия апаның ялга китүенә дә инде биш ел тулды. Коммунистик хезмәт ударнигы дигән мактаулы исемне хәзер кызы Роза йөртә. Аның рәсеме — берләшмәнең Почет тактасында.

Һәркемнең буш вакытларында яратып башкара торган шөгыле була. Роза Абдуллатыйпованың исә — китап уку.

— Күңелемә ошап китсә, китапны төннәр буе укыйм, — ди ул. Роза шигырьләрне дә бик ярата. Фабрикага эшкә килгән елларны үзешчәннәр концертында Тукай, Такташ, Җәлил шигырьләрен яттан сөйләгән.

— Менә шушы концертларда катнашып йөрүләр Дамир белән таныштырды. Мин сөйлим, Дамир җырлый торган иде, — ди Роза елмаеп.

Розаның да эштән кәефе кырылып кайткан чаклары була. Я мехның сыйфаты әйбәт түгел, я киракле өлге әзер булмый. Андый вакытларда Дамиры кызларына карый да «Ак калфак» көенә, «әниебезгә сүз әйтмиек, кәефе кырылган чагы», дип шаярта. Икесе бер фабрика коллективында эшләгәч, сөйләшер, киңәшер сүзләре дә күп аларның.

— Җиңел промышленность предприятиеләре буенча Бөтенсоюз ярыш инициаторы мех кисүче Фәүзәрия Мөхетдинованы беләсең бит инде. Мин дә аның «һәр эш урынында әйбәт сыйфатлы эш, югары нәтиҗәлелек» дигән башлангычына кушылган идем. Бүген менә остәмә әйбер кисә алмадым, бер-ике тиренең сыйфаты әйбәт булмады,— ди Роза иренә, борчылып.

* * *

— Роза, мин бүген соңрак кайтырмын, пневмолинияне эшләтеп карыйбыз... Мин сезгә китаплар алдым, язучыларның исемнәрен әйтмим, кайткач күрерсең,— диде Дамир төшке аш вакытында, хәйләкәр елмаеп.

Роза эштән кайтканда кызлары өйдә юк иде. Җиденче класста укучы кызы Люция хат язып калдырган: «Әнием, мәктәпкә дружина сборы үткәрергә киттем, аннан художество мәктәбенә дәрескә барам, Лилия — иптәш кызларында».

Люция дә, өченче класс укучысы Лилия дә отличницалар. Мәктәп җыелышларына барган саен Дамир белән Розага укытучылар рәхмәт сүзләре генә әйтәләр.

Кызлардан алда дөньяны балкытып Дамир кайтып керде.

— Булды, Роза, линиягә җан керде. Йонны күтәреп ташып йөрисе юк. Әлек юу участогына, аннан киптерү, пресслауга күчәчәк, — диде ул канатланып.

Шатлыкны уртаклашырга тупырдашып кызлары кайтып җиттеләр.

Кичке аштан соң Роза көндез Дамир алып кайткан төргәкне ачты. Анда А. Макаренконың «Педагогик поэма»сы, Л. Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» романы килеп чыкты. Шундук «Педагогик поэма»га чумды ул. Кызлар дәресләрен карарга утырдылар.

— Әни, бер генә минутка укуыңны куеп тор, менә кара әле, ничек ясадым, мин үскәч туннарны яңа фасоннар белән тегәрсез. Син менә шушы рәсемдәге кебек итеп кисәрсең, яме,— дип, алдына Лилиясе килеп басты.

— Әйдәгез, әйдә, безгә алмашка киләрсез. Абдуллатыйповлар династиясе дәвамчылары булырсыз, бәхет кошы сез дә мех фабрикаларында табарсыз, — дип сүзгә кушылды өстәл тирәсендә кәгазьләрен актарып кайнашкан Дамир.

Дамир бүген саннарын, сызымнарын калдырып торыр дип уйлаган иде Роза. Ә ул әнә тагын шуларга тотынган.

Дамир исә юеш тиреләрне чимал-буяу цехыннан киптерү цехына җиңел юл белән генә күчерү турында уйлана.

Венера КӘЛИМУЛЛИНА.

ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ!

Кичке сәгать дүрттә өстәлләр әзер иде инде. Шулай да борчылам: яшьләр алдында йөзгә кызыллык килмәсме! Безне — өлкәннәрне аңларлармы алар! Ел саен училище тәмамлаучы кызларны шушы Культура сараенда эшчеләр семьясына кабул итәбез бит, югыйсә. Ник дулкынланам соң!

Өстәлләрне кабат күздән кичерәм. Һәммәсе дә үз урынында кебек.

Күз алдыма каяндыр ерактан, тоныкына булып, икенче өстәл килеп баса. Сугыштан соңгы беренче еллар. Миңа да унсигез яшь — шушы ук училищены тәмамладым. Укытучыларыбыз, тәрбиячеләребез безне директор бүлмәсенә чакырдылар. Барып керсәк — исебез китте: матур итеп чыжлап-җырлап самовар утыра, өстәл уртасында каерып киселгән ипи телемнәре, вак-вак итеп, китеп-китеп кенә ватылган ап-ак шикәр өеме...

И, ул чәйнең тәмлелекләре!..

Халкыбызның элек-электән килгән яхшы гадәте буенча, училище җитәкчеләренең самовар янында безгә шулай изге теләк теләп, эшчеләр семьясына, мех фабрикаларына озатулары иде ул...

— Апа, без ялгыш кермәдек микән! — ди, уйларымны бүлеп, каяндыр каршымда пәйда булган кызларның берсе. — Без училищедан, кичәгә чакырганнар иде. Ә монда...

— Юк, кызлар, сез ялгыш кермәдегез. Үзегезгә ошаган өстәлләрнең берсен сайлагыз да утырыша башлагыз, — дим җиңел сулап.



Тугызынчы бишьеллыкта ике бишьеллык план үтәгән Фәүзәрия Мөхетдинова хәзер унынчы бишьеллыкның дүртенче елы өчен эшли.

Ниһаять, сәгать алтыны сукты. Беренче рәттәге өстәлләргә күкрәкләрен медаль һәм орденнар каплаган хезмәт ветераннарын утырттык. Аннан берләшмә җитәкчеләре, училище укытучылары, тәрбиячеләр, кунаклар, ә арырак — бүген генә училище тәмамлаган, иртәгә берләшмә цехларына аяк басачак яшьләр урнашты.

Һәм менә микрофоннан ягымлы гына ир-ат тавышы ишетелде:

— Тыңлагыз!.. Тыңлагыз!.. Олы бәйрәмебезне, бүген генә училище тәмамлаучы яшьләребезне эшчеләр семьясына кабул итү кичәсен башлыйбыз!..

Каршыбызда — ике кыз. Алар хезмәт алдынгылары, батыр хатын-кызларыбыз турында шигырь сөйлиләр...

— Берләшмә байрагын алып чыгарга!

Байрак алдында — уку отличнигы Фәридә.

— Без, училище тәмамлаучылар барыбыз да, бүгенге бәйрәмне оештыручыларга, укытучыларыбызга, берләшмә җитәкчеләренә олы рәхмәтебезне әйтәбез.

Моңа каршы училище директоры Рәмзи Шаһиволиев тавышы ишетелә:

— Эшче исеменә лаек булырга ант итегез!

— Яңа җиңүләр яуларга, мех берләшмәсенең хезмәт традицияләрен сакларга ант итегез!

— Коммунистлар партиясенең лаеклы кызлары булырга ант итегез!

Байрак үбеп, кыз ант бирә, ә аңа залдагылар тавышы кушыла. Кайтаваз булып, «Ант итәбез!» сүзләре яңгырый. Быргы, барабаннары белән пионерлар керә... Уку отличникларына Мактау грамоталары тапшырыла. Хезмәт ветераннары, укытучылар, алдынгылар чыгыш ясый.

Менә яшьләр алдына күкрәге III дәрәҗә Хезмәт Даны, «Почет билгесе» орденнары, медальләр белән бизәлгән 4 нче фабриканың мех кисүчесе Фәүзәрия Мөхетдинова чыга.

— Мин үзем дә, кызлар, сез укыган училищены тәмамлаган идем, — дип башлый ул сүзен. — Сезнең кебек яшьләргә остаз булып китүемә дә шактый гомер узды...

Әйе, коммунист Фәүзәрия бик шәп остаз да ул.

Моннан өч ел элек кенә училищедан килгән Фирдания Вәлиева иң яхшы сыйфатка гына ике норма бирүе белән дә, кичке мәктәпне тәмамлавы белән дә һәм, ниһаять, социалистик ярышта җиңеп чыгып, Бөек Октябрь революциясенең 60 еллыгы уңае белән, Ленин комсомолының партия Үзәк Комитетына язган рапортына кул куярга хокук алуы белән дә — Фәүзәриягә бурычлы. Сания Галиханова да, Миңҗамал Әхмәтшина да һәм тагын бик күпләр укуларын дәвам итүләре белән аңа, Фәүзәриягә бурычлылар...

— ...Килегез, кызлар, курыкмыйча килегез! Даны бөтен дөньяга таралган орденлы мех берләшмәсе фабрикалары сезне көтә, — дип бетерде сүзен Фәүзәрия.

Аның өчен горурланып утырам: кыю да, тыйнак та безнең Фәүзәрия! Тугызынчы бишьеллыкта ике бишьеллык план үтәве, унынчы бишьеллыкның инде дүртенче елы өчен эшләве турында яшьләргә әйтмәде ул. Сөйләүдән бигрәк эшләп күрсәтергә ярата. Былтыр Мөхетдинованың хезмәт алымнарын өйрәнергә бөтен союздан җыелганнар иде. Алдынгы мехчылар Фәүзәрия тәҗрибәсен өйрәнеп кенә калмыйча, аны ярышка да чакырдылар. Бу ярышта да Фәүзәрия Мөхетдинова җиңде.

Менә, бәхетле яшьләр, сезнең остазларыгыз белән ил горурлана, дим эчемнән генә.

Кичәнең икенче өлеше концерттан тора. Җыр-бию, уен-көлке...

Залдагылар өстәлдәге нигъмәттән авыз иткәләп, җыр тыңлыйлар, ял итәләр...

Бераз гына борчылып һәм сөенеп кайтырга чыктым. Урамнар өстенә инде төн иңгән. Алдымнан кызлар атлый. Аларның көлүләре аралаш горур сүзләре дә ишетелә.

— Менә, бүгеннән без дә эшче бит!..

— Бик борчылган идек, — әйбәт тә булды инде.

— Беләсезме, кызлар, бер-ике генә ел эшлим дә, аннан укырга китәрмен... Институтка дип уйлаган идем мин. Шушы бәйрәмгә, кичәгә хәтле... Бигрәк зурладылар, хәзер эшләп күрсәтергә кирәк инде! Читтән торып укырмын.

— Әйе шул. Әнә Антонина Колиуш дигән апа үзенең чыгышында әйтте бит: 3 нче мех фабрикасының директоры Александра Николаевна Федорова безнең училищедан соң кичке мәктәпне, техникумны, институтны, аннан читтән



Остазның һәр сүзе, хәрәкәте яшьләр өчен олы бер сабак.

торып аспирантура тәмамлаган. Алсу Вәлиева да безнең училищены тәмамлагач, кичке техникумны бетергән, ә хәзер институтның кичке бүлегендә укый икән.

— Юк инде, кызлар, бер кая да китмәячәкбез. Безнең эш урыннарыбыз — мех фабрикалары! Ә укуны, чыннан да, кичләрен дәвам итәрбез.

Уйларым тагын яшьлегемә кайта...

4 нче мех фабрикасына кайчандыр мин дә дулкынланып һәм өметләнеп аяк баскан идем. Остазым Мәйсәрә апа кулыма тукымалар тоттырды да, бүрек калфагын тегү серләренә өйрәтә башлады. Булмый гына бит, тегә алмыйм: я тукыма җыерыла, я җөйләрем дөрес ятмый, я материалым җитми кала. Ә остазымның кулларына күз иярми...

Бер елдан минем дә рәсемем фабриканың Почет тактасында, остазым белән рәттән куелган иде инде.

Хатирәләр... Хатирәләр... Бу мех эшен, аның кешеләрен яратуымны кайчан аңладым соң мин? Мехчылар съездына делегат итеп сайлангандамы, әллә фабрика профсоюз комитетының председателе яки партия оешмасы секретаре булып эшләгәндә белдемме мин моны! Әллә утыз елдан артык мехчылар эшендә эшләгәч, хәзер генә — кызлар сүзен тыңлап кайтып килгәндә төшендемме мин моңа?..

— Беләсезме, кызлар, бу мех берләшмәсендә әйбәт эшләүчеләрне күрә дә беләләр икән бит. Теге атаклы Фәүзәрия Мөхетдинова дигән апага Мәскәүдән үз исеменә путевка җибәргәннәр. Пицунда дигән җирдә ял итеп кайткан икән ул, — ди кызларның берсе.

— Ә генеральный директор Нәүфәл абый Рәхимов, безнең мехларыбыз дөньякүләм күргәзмәләрдә дипломнар белән бүләкләнде, Бельгиядә Алтын медальгә лаек булды, ди... Кызлар, соңгы елларда гына да Казан мехлары 76 мәртәбә күргәзмәдә катнашкан икән бит. Татарстан мехлары Франция, Америка, Польша, Аргентина, Япония, Куба, Италия кешеләрен дә шаккатырган икән шул, — ди кызларның икенчесе.

Җиңел булып китте. Әйе, болар эшләячәк, һичшиксез, эшләячәк. Әле ничек кенә эшләрләр! Алар теккән яңа бүрекләрне, алар теккән яңа туннарны күргәндәй булам.

Хәерле сәгатьтә, кызлар. Хәерле юл сезгә, дускайларым, дим.

Рәмзия АИТОВА,
Казан мех берләшмәсенең
Культура сарае директоры.



— Һәр секундның, һәр минутның кадерен белсәң генә, ике норма, ике план үтәп була,— ди Луиза Хәерова.

Р. ЯКУПОВ фотолары.



Минзия Вәлиева күптәнге гадәте буенча ферма сукмагына беренчеләрдән булып чыга. Чәчләренә инде чал кергән булса да, яшьләргә хас җитезлек һәм ныклык сизелә аның адымнарында.

Утыз сигез ел буена җәйге матур таңнарны да, кышкы күз ачкысыз бураннарны, суыкларны да күп күрергә туры килде аңа. «Энергетик» совхозының товарлыклы-сөтчелек фермасына җитәкчелек итә башлаганына да егерме елдан артык вакыт узды инде.

Менә бүген дә Минзия фермага караңгылы-яктылы килеп җитте. Беренче савымчылар килеп кергәндә абзарларны иңләп, малларны барлап чыккан иде инде. Ул шушы көннәрдә пенсиягә чыгарга җыенган хезмәттәше Заһидә Галәветдинова группасы янына тукталды.

— Синең группадагы сыерларны кемгә бирергә икән? — дип сүз башлады бригадир. — Әллә, мин әйтәм, бераз үзең эшлисеңме?

— Үземнең дә исәбем шулайрак... — диде аңа хезмәттәше.

Бригадир аннан соң азык әзерләү цехына юнәлде. Сөтнең исәбен алышты.

Кыскасы, аның һәр эш көне әнә шулай төрле мәшәкатьләр белән үтә. Шушы кайгыртучанлыгы, са-

КОЛХОЗЫБЫЗГА РӘХМӘТ!

Азнакай районының «Коммунизмга» колхозы балаларга зур шатлык бүләк итте. Чаллы авылы уртасындагы ике катлы зур гына таш бинада балалар комбинаты ачылды. Әле кайчан гына без мондый биналарны дәреслек китапларында гына күрә идек. Ул рәсем хәзер дә күз алдында: катлы-катлы йортлардан торган иркен урам...

БРИГАДИР

вымчылар белән кулга-кул тотынып эшләве, кешеләрнең күңелен таба белүе хезмәттә аңа уңышлар китерә. Бригада терлекчелек продуктлары җитештерү буенча социалистик ярышта һәрчак җиңеп чыга. Совхоз җитәкчеләре аны ихтирам итәләр, олылыйлар. Минзия Вәлиева коммунист буларак, партия оешмасы тормышында актив катнаша, ул — совхоз парткомы члены.

— Мин фермага унике яшемдә йөри башладым, әни янына килә идем, — ди ул үткәннәрен искә төшереп.

Шулай итеп яшь кыз фермага ияләнеп китә, әнисе белән бергәләп сыер сава. Әмма фермада аңа озак калырга туры килми.

1940 елның көзендә оештырылган механизаторлар әзерләү курсына кергән егерме кыз арасында ул да була. Ә язын механизатор профессиясен алып чыга. Совхозда хатын-кызлардан бригада оештырыла, беренче чыныгу алына. Бөек Ватан сугышы башлангач, тракторлар кызлар кулына күчә.

— Запас частьлар җитешми иде. Шулай да техниканы эшләтергә кирәк иде,— ди ул авыр сулап.

Атналар буена басудан кайтып кермәгән чаклар була. Минзия тракторчы булып 1948 елга кадәр эшли. Көзен аны тагын фермага сыер саварга чакырып алалар. Хезмәттә чыныккан көчле куллар сынатмыйлар. Тырышлык бушка китми, Минзиянең күрсәткечләре елдан-ел күтәрелә бара.

1955 елда совхоз дирекциясе Минзия Вәлиеваны үзе эшләгән фермага бригадир булырга тәкъдим итә. Директор Яков Максимович Никудимов: «Тырышлыгың зур, иптәшләрең таныш, бергәләп эшләрсез, кирәк икән без дә булышырбыз»,— ди.

Минзия Вәлиева җитәкчелек итә башлагач, терлекчелектә зур үзгәрешләр була. Иркен, якты абзарлар төзелә, авыр эшләр механикалаша. Терлекләрнең продуктлылыгы да бик нык арта. Минзия савымчы булып эшли башлаганда һәр сыердан елына 1000—1200 килограмм сөт алынса, тугызынчы бишьеллык ахырында бригада һәр сыердан 2834 килограмм сөт сауды. Ә коммунист Мария Терехинаның күрсәткече 3204 килограммга җитте.

Тугызынчы бишьеллыкта ирешкән уңышлары өчен бригадирга «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале янына «Почет билгесе» ордены өстәлде.

Бригада унынчы бишьеллыкны да уңышлы башлап җибәрде. Совхоз яңа бишьеллыкның беренче-икенче елында дәүләткә сөт сату планын арттырып үтәде. Бу уңышларда коммунист Минзия Вәлиева бригадасының да өлеше зур, әлбәттә. Шушы фидакарь хезмәте, Бөтенсоюз социалистик ярышында җиңеп чыгуы өчен бригадир хөкүмәтебезнең тагын бер олы бүләге — Хезмәт Кызыл Байрагы орденына лаек булды.

Унынчы бишьеллыкның өченче елы бара. Минзия Вәлиева җитәкчелегендәге коллектив Киев өлкәсе ферма эшчәннәренең терлекчелек продуктлары җитештерүне арттыру турындагы чакыруына җавап итеп алган йөкләмәләрен уңышлы үтәү өчен көчен кызганмый. Бу, һичшиксез, үзенең җимешләрен китерер, алга куелган бурычлар үтәлер. Чөнки коллектив белән коммунист, үз эшен чын күңелдән башкаручы, хезмәттәшләренең ихтирамын казанган кеше җитәкчелек итә.

Б. ИСЛАМОВА,
КПССның Әлки райкомы инструкторы.

Урам буйлап машиналар чаба. Рәсем астына «Шәһәр күренеше» дип язылган. Ә хәзер әнә шул күренешне безнең авылга килеп күрегез. Ике катлы урта мәктәп, ике катлы административ бина, ике катлы кибетләр, ике катлы зур культура йорты, ике катлы балалар комбинаты бар хәзер бездә. Бу комбинат шәһәрнең иң яхшы дип саналган балалар бакчаларыннан һич тә калышмый. Һәр иртәдә игенчесе, терлекчесе, авыл интеллигенциясе сабыйларын җитәкләп шуның янына агыла. Алгы якта чишенү бүлмәсе. Анда һәрберсенең үзенә аерым кием шкафы куелган. Аны узуга иркен уен залы. Нинди генә уенчыклар юк анда: курчаклар, нәни машиналар, рәсемле китаплар, уенчык атлар — барысы да аларныкы, рәхәтләнеп уйнасыннар гына. Каршы яктагы зур ишек спорт залына алып керә. Идәненә затлы келәмнәр җәелгән, музыка кораллары белән җиһазландырылган ул. Сәламәт тәндә сәламәт акыл. Балалар сабый чактан ук чыныгып, таза булып үссеннәр өчен бөтен мөмкинлекләр дә тудырылган биредә.

Ә икенче ишек форточкаларын ачып җилләтелгән йокы бүлмәсенә ачыла. Кечкенә кроватьларга ак җәймәләр җәелгән, йомшак мендәрләргә башларын салып, җылы юрганнарга төренеп йоклыйлар алар монда. Ашханәсенә генә күз салыгыз. Сабыйларның дөрес туклануына аеруча зур игътибар бирелә. Елның ел буена өстәлдән витаминга бай булган яшелчә-җимеш өзелми. Икмәктән алып ите, сөте, йомыркасы, кыяры, помидоры, карлыганы, балы, җиләге — барысы да колхозның үз байлыгы. Ел-лык яшелчә җимеш комбинатының үз подвалында саклана. Шәһәр балалары җәен шәһәр шау-шуыннан тузаннан арыну өчен дачаларга озатыла. Ә безнең дачабыз комбинатның үз ишек алдында ук. Анда яшеллек, анда комлык, анда бассейн...

Авыл балалары мәктәпкә озатылганчы махсус педагогик белеме булган тәрбиячеләр кул астында тәрбияләнә. Менә утызынчы ел инде балалар бакчасында эшләүче Миңнур апа Хәкимова, Әлфия Мусиналар ата-аналарның иң якын таянычлары. Ә утыз ике ел буена няня булып эшләүче Мәрьям Сәхапованы кечесеннән алып олысына кадәр хөрмәт итә. Музыкант Рөстәм Исламов сабыйларга кече яшьтән эстетик тәрбия бирә. Иртәнге физзарядкалардан алып музыка занятиеләре үткәрү, концертларга хәзерләнү эшләре барысы да аңа йөкләтелгән. Шуның өстенә авыл тирәли кечкенә генә сәяхәтләр дә ясала. Авылыбызның Культура йорты каршында бөек юлбашчыбыз Ленинга мәһабәт һәйкәл куелды. Һәйкәл итәгендә чәчәкләр... Алар балаларның бөек Ильичка булган бүләкләре, рәхмәтләре. Авылның үз паркы бар. Ул 30 гектар җирне биләп тора. Парк түренә сабыйларның якты киләчәге өчен көрәшеп һәлак булган бабаларына һәйкәл-обелиск куелган. Яшь буын барысын да күреп, тоеп үссен! Күкләре аяз, күңелләре көр аларның. Үзләренә әнә шундый яхшы шартлар тудырган туган колхозлары, аның җитәкчесе орденлы председатель Сәгадәт Аппаков, авыл Советы председателе Мөгаллимә апа Латыйповага да рәхмәтләре зур аларның.

Дамирә КАҺИРОВА,
балалар бакчасы комбинаты директоры.

ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВ

ИЛ КАЙГЫСЫ

ХИКӘЯ

Адәм баласы пыяла тартма эчендә яшәми, ул халык белән бергә тора, аның кайгы-хәсрәтен, шатлык-рәхәтен кече яшьтән күреп үсә. Әле кичә генә авылда һичбер хәвеф-хәтәр юк иде. Төнлә, көтмәгәндә, янгын чыгып, тәрәзә төпләрендә кына гөлләр чәчәк атып торган ике өй урынында кара кисәүләр белән көл генә калды. Хуҗаларның куллары салынган, башлары иелгән, алар нихәл итәргә белмиләр, кара кисәүләрне бер күтәрәләр, бер ташлыйлар... Менә бу фәкыйрь өйдә икенче төрле төзәлмәс кайгы — әле яңарак кына гаилә башлыгын җеназа белән күтәреп соңгы юлга алып киттеләр. Тол калган хатын, сукыр тәрәзә каршына басып, буп-буш урамга карый. Ул бер нәрсә күрми бугай, күзләреннән кайнар яшь ага, иреннәре калтырый. Ул бәргәләнми, суккаланмый, ләкин бу аның кайгысын гына тирәнәйтә. Итәгенә берсеннән-берсе кечкенәрәк дүрт баласы ябышкан — ничек инде бичара ана бу мескеннәрне асрар?!. Ә бу йортта тагын башка бер хәсрәт. Ир канаты — ат диләр. Бу хуҗаның да мескен генә аты бар иде. Ул сукасын да сукалый, кырдан иген дә алып кайта иде. Җомга көн кырда утлап йөргән җирендә яшен сугып үтергән. Хуҗа канаты сынган кош кебек кайтып керде. Кулында йөгән, тик ул инде бернигә кирәкми...

Шуңа охшашлы аяныч хәлләрне мин бала чактан җитәрлек күреп үстем. Тик бер нәрсә минем башыма сыймый иде: ап-ак сакаллы хөрмәтле картлар сабыр итәргә өндиләр, башыахыры шул булсын диләр, ходай үзе бирә, үз ала, тәкъдиребездә шулай язылгандыр, берни эшләп булмый, барысы ходай тәгалә иркендә, имеш. Карышырга ярамый, ходай әмеренә каршы тел әйтсәң, тагын да начаррагы булуы мөмкин, диләр.

Мин карышмыйм да кебек, ләкин ходайга бераз үпкәлим: алырга булгач, нигә бирә? Барысы да аның иркендә булгач, нигә кешеләргә шатлык кына җибәрми, нигә ут-күз чыгара, нигә кешеләрне үтерә, яшен яшьнәтә, игеннәрне харап итеп, боз яудыра?

Билгеле, болар аптыраган, тормышның нәрсә икәнен белмәгән бала-чага уйлары гына. Зурларга төрле сораулар бирә башласаң, чү, тиле, ходай эшенә тыгылып буламыни, дип кырт кисәләр. Моңарчы тормыш нинди матур иде, ә хәзер мин аңардан курка башладым. Кешегә һәрвакыт ниндидер кара өрәк янап тора икән. Аның бер дә көтмәгәндә бәреп егуы мөмкин, моңа ничек каршы торырга, ничек сакланырга кирәк икәнен дә белмисең.

— Монысы ярый, монысы аерым кешеләр, бәхетсезләр кайгысы гына,— диләр хөрмәтле картлар, минем шикелләләрне тагын да тирәнрәк аптырашка төшереп.— Ил кайгысы була күрмәсен, менә анысы хәтәр. Бик хәтәр! Иле юкның — көне юк.

Без, балалар, ил кайгысын күрмәдек әле, аны күз алдыбызга китерә алмыйбыз. Ап-ак сакаллы картлар әйткәч, чыннан да бик куркынычтыр ул.

Без үскәндә сугыш та, ачлык та булды. Сугыш бездән кайдадыр еракта узды, без аны үз күзебез белән күрмәдек. Малайлар да, өлкәннәр дә, ачулары килсә, сугыша. Шуның шикеллерәкме икән ул мылтык белән сугышулары? Ачлык елларында алабута икмәге дә, тозсыз аш та ашадык. Шулай да безнең якларда ачлык ул кадәр дәһшәтле булмады. Дөрес, теләнеп йөрүчеләр күбәйде. Өлкәннәр аларны мескеннәр, бәхетсезләр дип атыйлар иде. Моңарчы бәхет турында әлләни уйланган юк иде. Безгә, балаларга, ул алай кирәк тә түгел иде. Кузна уйнаганда: «Бәхетең бар икән, малай, шуңа күрә син отасың»,— диләр иде. Баксаң, ул бәхет дигәннәре зуррак нәрсә икән.

Малай халкы андый хәтәр нәрсәләрдән ераграк торырга тырыша. Әнә көн нинди матур, инеш буена төшәсең, балык тотасың, су керәсең. Ун-унбер яшьлек авыл малаена тагын нәрсә кирәк?

Без күбрәк гамьсезлек дөньясында яшәсәк тә, тормыш һаман катлауланганнан-катлаулана бара, әкрен-әкрен балаларны да үз эченә тарта иде. Минем тормышымда зур үзгәреш булды. Мин гаиләдә өлкән бала идем.

— Җитәр, улым, шар сугып, кузна уйнап вакыт үткәрергә. Син зур инде. Авылда укуларның рәте-чираты юк, русча да өйрәнә алмыйсың, татарча да. Мәскәүгә алып барам үзеңне. Анда тизрәк күзең ачылыр,— диде әти.

Мәскәүгә барганчы, андагы тормыш миңа хыялый бер дөнья кебек тоела иде. Ләкин Мәскәү тормышы — ике яклы пычак икән. Бер карашка, ул чыннан да хыялый. Керосин да салмыйсың, ә лампочкалар шундый якты яна. Төймәгә бармак белән басасың, ут сүнә, тагын басасың — яна. Чыра яндырган авыл малаена бу — могҗиза. Ә урамда трамвайлар челтер-челтер йөри, матур файтуннарына атлар да җикмәгән, үзләре тәгәри. Кибетләре тагын — күз явын алырлык, авылдагы тавык кетәге шикелле «лаука» түгел. Күмәчне дә үзең пешермисең, кибеттән генә чыгып аласың, бәрәңгене утырту да, казу да юк — кибеттә күпме теләсәң... Икенче карашка, син шаккатасың — өең көндез дә ут янып торган подвалда. Кысан, караңгы. Мәскәүнең үз кешеләре югары катларда торалар. Алар алдан килгән шул, без соңга калганбыз.

Малай кешегә иң кыены — уйнарга урын, иптәшләр юк. Ишегалдында малайлар күп күбен дә, мин аларга читтән генә карыйм шул, уеннарына катнашмыйм, чөнки сөйләшергә тел белмим. Аларның кайберләре яныма килеп нидер әйтәләр, мин, авызыма су капкан шикелле, эндәшмим. Кулбашына төртеп китүчеләр дә, үчекләүчеләр дә бар. Каршы сугасы да килә, шүрлим дә. Алар күбәү, мин — ялгыз.

Мәктәпкә йөрмим әле, өйдә генә укыштыргалыйм, аннары бүлмәне җыештырам, идәннәрне себерәм, башка вак-төяк эшләрне эшлим. Мине япи кибетенә алып баралар. Яхшы кара, тиздән үзең генә кибеткә йөрерсең, диләр. Вывескаларны укырга өйрәтәләр. Иҗекләп кенә булса да укый беләм, тик мәгънәләрен генә төшенмим. «Хлеб, булочки» дигәннәрен генә аңлый башладым.

Кыш һаман зәһәрләнә бара. Урамга чыгарлык та түгел — яндыра. Менә шул көннәрдә Мәскәү өстенә әйтерсең карасу-соры җәймә яптылар. Мин, бала кеше, баштарак берни абайламый тордым. Өлкәннәр нигәдер тавышларын әкренәйтеп, пышылдап кына сөйләшәләр, әйтерсең, өйдә авыру бар да алар аны бимазалаудан сакла624налар.

Көн урталарында, бүлмәдә берүзем калгач, урамга чыгарга булдым. Миңа рөхсәт итәләр иде, тик ерак китәргә кушмыйлар, адашырсың, диләр.

Урамда да гадәттәге шау-шу юк, кешеләр сөйләшми генә үтәләр, карашлары аска төбәлгән, башлары иелгән. Йортларда кара тоткан кызыл флаглар. Мин аларны беренче күрәм, нәрсә икәнен аңламыйм. Кар яумаса да күктән сыкы коела, кешеләрнең бүрекләре, шәлләре, якалары ап-ак. Минем дә керфекләр бер-берсенә ябыша башладылар, ә карт кешеләрнең мыек очларында бозлар. Үзләре моны сизмиләр дә шикелле.

Ахыр килеп, минем күңелемә дә курку төшә башлады. Тыкрык очына кадәр барасы килә дә батырчылык итмим. Анда нигәдер халык гадәттәгедән күбрәк күренә, трамвайлар йөрми, тыкрык башында извозчиклар да юк. Мин инде аларның тимер чаналарына берничә утырганым бар. Гадәттә мунчадан кайтканда извозчик ала идек.

Парадный төбенә дворник бабай чыкты. Миңа русча нидер әйтте. Мин, билгеле, төшенмәдем. «Азяп» дигәнен генә аңладым шикелле, туңгансың бит, дия иде ахрысы. Шуннан ул мине, иңбашларымнан тотып, капкага таба алып китте, тагын нидер әйтте, мин «домой» дигәнен генә төшендем.

Бозланып бер-берсенә ябышкан керфекләрем аша тагын кара тоткан флагларга карап алдым. Дворник бабай, минем карашны тотып алып:

— Горе, сынок, горе! Ленин умер, — диде.

Бу сүзләрне, шулай ук, тулысынча аңламадым. «Сынок» белән «Ленин» дигәнен генә төшендем. Ләкин Ленинга ни булган?

Өйгә кергәч, керфекләргә каткан бозларны бармакларым белән сыпыра башлаган идем, кинәт бармакларым үтереп сызларга тотынды. Мин үкереп елап җибәрдем.

— И бала, бала, — диде күршеләргә кунакка килгән Бәлхия карчык, — ходай тәкъдиреннән берни эшләтеп булмый шул, без түгел, Ленин бабайлар да үләләр.

Мин кычкырыбрак елый башладым. Бармакларым чамасыз әрни, гүя өзелә иде.

— И, бахыр, урамга чыккан идеңмени, бармакларыңны туңдыргансың ич. Хәзер кар алып керәм. — Бәлхия карчык тиз генә ишек алдына чыгып, бер кружка кар алып керде.— Менә яхшылап ышкы, хәзер үтәр.

Мин кар белән бармакларымны ышкый башладым. Керфекләремдәге бозлар үзләре эределәр.

Ниһаять, сызлау басылды, тик күңелдәге курку кимемәде. Мин әле Ленин бабайның үлеме — ил кайгысы икәнен аңламый идем. Аннары башка икенче төрле уйлар тула. Монда да җеназа алдыннан безнең авылдагыча ике малай: «Яхшы кеше иде, яхшы кеше иде!» — дип кычкыра баралармы икән?

Бүлмәгә кешеләр кайта башлагач, миңа җан кергәндәй булды. Өлкәннәр һаман караңгы чырайлы, һаман пышылдап кына сөйләшәләр, көлмиләр, шаян сүзләр әйтмиләр. Ә мин аларның көлеп сөйләшүләрен яратам, алар гаҗәп үткен сүзле. Бүген ашны да ничектер тәлинкәләренә карап кына ашадылар, чәй дә телләрен чишмәде.

Әтигә ияреп, яңа кешеләр килгән иде. Икесен инде күргәнем бар, берсен беренче күрәм. Зур такыр башлы. Кашлары белән мыегы кап-кара, чал керә башлаган, йөзе — кара-туткыл. Тавышы бераз карлыга төшкән, салкын тидергән ахрысы. Өлкәннәр аңа хөрмәт белән карый, моны мин беренче сүзләреннән үк сиздем.

— Ленин да үлгәч, безгә ни кала, — диде ул, беркемгә дә карамыйча.— Живой кеше бит һаман бәхет көтә. Ленин бөтен ярлыларга бәхет өләшәм дигән иде... Менә ул ничек була бу тормышта. Безгә бәхет ансат кына тими шул.

— Ленин не умер, Ленин живой! дип язган гәзиттә эре хәрефләр белән, — диде әти. — Мин вак хәрефләрен укый алмыйм, эреләрен генә. — Аның күзләрендә сорау һәм көтү.

— Урыслар шулай әйтә инде, Сәйфи. Безнеңчә әйтсәк, күңелдә живой була.

Бу сүзләр мине беркадәр юата. Дөрес, барысын аңлап бетермим. Күңелдә ничек тере булалар тагы? Шулай да Ленин бөтенләй үлмәгән икән, дип уйлыйм.

Икенче көнне өлкәннәр, Ленинны карарга барабыз, дип сөйләнә башладылар. Мин алардан мине дә алуларын инәлеп-инәлеп үтенергә тотындым.

— Куй, юкны сүләмә, улым. Кем сине анда карасын. Мин бармыйм, миңа эшкә килергә, анда күз-колак булырга куштылар,— диде әти.

— Сәйфи абзый, үзем алып барам,— диде күрше егет.

Әти артык каршы килмәде.

Һава бүген дә салкын, әмма кичәге кебек түгел шикелле. Аннары бүген мин җылырак киенгән идем, кулда йон бияләй, бүрекнең колакчыннары төшереп бәйләнгән, муенда шарф та бар. Борын белән күзләр генә күренә.

Урамда халык кичәгедән дә күбрәк. Кешеләр ташу кебек агыла — бар да бер якка — үзәккә таба. Без дә аларга кушылдык. Туктамыйлар, ашыгалар. Мин хәтта бераз тирләдем. Болай булгач, тиздән барып та җитәрбез, Ленинны да күрербез. Мин әле һаман аны үле итеп күз алдына китерә алмыйм.

Урамда халык артканнан-арта. Ирләрнең йөзләре кырыс, хәсрәтле, хатын-кызлар күз төпләрен сөртеп-сөртеп алалар. Халык арасында кайчак балалар да күренгәли. Алар инде Мәскәү малайларыдыр, бөтерелеп йөриләр, минем кебек абыйлары кулына чытырдап ябышмаганнар.

Бу кадәр халыкны һичкайчан күргәнем юк иде, өйләрдә бер кеше дә калмагандыр кебек. Бер йортка ничек сыярлар, анда бит инә төшәрлек тә урын булмас, дип уйлыйм, Ленинны күрә алмабыз, дип куркам.

Шактый озак торабыз. Мин инде туңа башладым, калтырата. Күзләремдә яшь тә күренде ахрысы. Бер рус абый, башымнан сыйпап, нидер әйтте. Мин эндәшмәдем.

Инде караңгылата. Шунда мин чынлап торып елый башладым. Мең бәла белән халык арасыннан читкәрәк чыгып, ниндидер тыкрыкларга, ишек алларына керә-керә өйгә кайтып киттек.

— Бик туңдыңмы? — дип сорады абый. Минем җавап бирерлек тә хәлем калмаган иде.

Икенче көнне иртән тагын Ленин бабайны карарга барырга җыендым. Ләкин өлкәннәр минем белән сөйләшеп тә тормадылар.

— Кичәге тамашаны оныттыңмыни? — диде берсе миңа.— Әтиең кунарга да кайтмады. Өйдә генә утыр, беркая чыкма. Я авырырсың тагы.— Минем күзләр яшьләнә баруын күреп: — Бүген без үзебез дә бармыйбыз, барыбер кереп булмый,— дип өстәде.

Бүген дә халык күп, сөйләшмиләр, чырайлары караңгы, башлары хәсрәттән иелгән, ә йөрәкләрендә ут дөрли бугай, урамнардагы учаклар кебек.

Бер учак янында минем яшьләр өч-дүрт малай күренде. Мин дә, курка-курка, алар янына килдем. Шунда әллә кайдан тагын бер малай атылып чыкты. Аның битләре кып-кызыл, кара күзләре елтырый, ә борын очы шадра. Бүрегенең колакларын да бәйләмәгән, берсе югары күтәрелеп тора, икенчесе түбән салынган.

— Әйдә әле икәү! — һәм җиңемнән тартты. Мин аңа карышмадым, дөресе, карыша алмадым, янып торган кара күзле, шадра борынлы бу малай я куркак дип үчекли башлар, дип шүрләдем.

— Син татар малае бит, исемең ничек? Минеке — Бикми... Любянка аркылы барып булмый, җибәрмиләр. Ниглинныйга сыптырабыз.

— Аннан да җибәрмәделәр.

— Ә без ишек аллары аркылы, аннары кырышага менәбез. Өй түбәләреннән Охотныйга ук чыгып була. Мин юлны беләм.

Мин нигәдер туктап калдым.

— Нәрсә, әллә шөр җибәрәсеңме? — Бикминең җете-кара күзләре генә түгел, шадра борыны да миннән көлә иде кебек.

Кайсы малай «куркам» дип әйтә ала!

— Әйдә! — дидем тәвәккәлләп.

Без ниндидер ишегалларына кердек, берничә җирдә коймалар аша сикереп чыктык. Хәзер мин бер нәрсә турында уйламадым, бу ут-малай артыннан кыю атладым.

Бер ишегалдында туктадык.

— Әнә өй түбәсенә менә торган баскыч. Тиз бул, дворник әләктерә күрмәсен. Бик усал, колакны бора.

Мин күзләремне тимер баскычтан ала алмадым. Һай, биек! Күккә терәгәннәрмени. Минем андый биеккә һичкайчан менгәнем юк. Шүрлим дә, иптәшем алдында куркак буласым да килми. Ә Бикминең кара күзләре янып тора, шадра борыны шундый мәзәк, очарга җыенган шикелле. Ул, мөгаен, бер нәрсәдән курыкмыйдыр. Күз ачып йомганчы урыныннан кузгалды да баскычның шактый биек аркылы тимеренә сикереп ябышты, аннары югары менеп тә китте.

— Әйдә әле, курыкма! — дип кычкырды. Тавышында мине дәртләндерү дә, аз гына көлү дә яңгырады кебек.

Мин, бар ихтыярымны учка җыеп, йөгереп килеп баскычның аркылы тимеренә ябыштым. Оятыма каршы, күтәрелә алмадым. Тешләремне кысып тагын ябыштым, тагын уңышсыз. Тирә-якка күз йөртәм. Аяк аска куярлык бер генә нәрсә дә күренми. Тагын сикердем һәм ничектер күтәрелдем. Бераз күтәрелгәч, аска караган идем, тез буыннарым калтырый башлады. Ә Бикмәй югарыдан кычкыра:

— Аска карама, югары мен — курыкма!

Бу юлы шадра борын ачыктан-ачык мыскыллый кебек тоелды. Ә мин үзсүзле малай. Сугыша башлагандагы шикелле, аскы иренемне тешләп, югары менеп киттем. Ниһаять, мин дә түбәдә!

— Батыр икәнсең,— диде Бикми бу юлы үчекләмичә.— Бер малай кичә яртысына да менә алмады. Нәзберек.— Һәм мыскыллап черт итеп төкерде.— Андыйлар белән берни эшләп булмый.

Морҗа янына менеп утырдык та аска карап тора башладык. Бөтен дөнья кешеләре урамга чыккан ахрысы. «Менә ил кайгысы нинди була икән!» — дип уйладым. Шул турыда сөйләргә җыенган гына идем, Бикми урыннан торды:

— Ә хәзер миннән калма — киттек.

Минем аякларга нидер булган иде ахрысы, мин Бикми кебек күз ачып йомганчы торып аякка баса алмадым. Баскач та чак егылып китмәдем. Ул арада шадра борын күздән дә югалды. Мин өй түбәсендә бер ялгызым калдым. Кая барырга, нишләргә? Кычкырып карадым, җавап тавышы ишетелмәде. Кырыйга килеп, аска карарга курыктым...

Шуннан соң ни булганын бик томанлы хәтерлим. Ничек өй түбәсеннән мәтәлеп төшеп харап булмаганмын — белмим. Нинди көч мине кире баскыч янына алып килгәндер, нинди тәвәккәллек белән кире төшә башлаганмын, ничек башым әйләнмәгәндер дә түбән очып китмәгәнмендер — алла белә. Җиргә баскач та бөтен гәүдәм калтырый иде. Юк, мин туңмый идем, бу ниндидер башка нәрсәдән калтырау иде.

Шунда минем яныма олы гына бер рус хатыны килде. Минем йөзем, ахрысы, үлекнеке төсле агарган булган, хатын, борчылып, нидер сорады. Минем күзләремнән яшь ага башлады.

— Не плачь, милый. Ленин жив, Ленин не умер!

Мин, яшемне йотып:

— Домой,— дидем.

— А где живешь?

— Аш, Аш,— дидем, Ащеулов дигән тыкрыкны әйтә алмыйча. Аннары зур урамны хәтерләдем.— Эстретинка.

— Ах, Сретенка,— диде хатын, кулымнан тотып, арткы урамга алып чыкты. Биредә дә халык бик күп иде. Без, кысыла-кысыла, кайда проходной ишек алларыннан үтеп, «Эстретинкага» таба киттек. Бик озак баргач кына, таныш урам күренде. Миңа җан керде.

— Ыспасиба, тетенька! — дидем дә, хатынның кулыннан ычкынып, йөгереп киттем — монда инде халык тагын да азрак иде...


Ул хәсрәтле көннәр минем күңелемдә мәңгегә онытылмаслык булып калды. Ул чакта мин Ленинны, билгеле, күрә алмадым. Соңыннан мавзолейда да булдым. Әмма ил кайгысы — бөтен күкне каплаган болыт икәнен, бөтен халыкны җылы өйләреннән урамга чыгаруын, ил кайгысын ялгыз-ярым күтәреп булмаслыгын, халык белән бергә-бергә бераз җиңелрәк икәнен беренче тапкыр аңладым. Тагын халыкның Владимир Ильич Ленинны никадәр якын итеп яратканын төшендем. Әле бик озак, бик озак минем күз алдымда урамнар тулы халык торды. Ә төшләремдә тагын һәм тагын тимер баскычтан өй түбәсенә мендем. Төшнең шул ягы яхшы — анда курыкмыйсың, барысы бик ансат эшләнә. Өй түбәләреннән берсеннән икенчесенә гүя очып кына үтәсең. Елтыр кара күзле, шадра борынлы Бикми дә минем янда кебек. Без аның белән өй түбәсеннән халык диңгезенә бик озак карап торабыз, имеш.

Ул көннәрдә мин, мөгаен, балалыгымнан үсмерлегемә атлаганмындыр.

1977 ел.



М. РӘХИМОВ. Ульяновлар гаиләсенең, Казанга килеп төшкәч, беренче башлап яшәгән йортлары.



ЫШАН, ӘНИЕМ!

Үземнең иң кадерле кешем, әнием турында сезгә дә сөйлим әле.

Минем әнием унтугыз ел буе Ишбирде авылында фельдшер булып эшли. Эшли башлавының беренче елларында кыенга килсә дә, максатына тугрылыклы булып калган.

Авыл фельдшерының хезмәте җаваплы. Һәр кешенең сәламәтлеге — аның кулында. Фельдшер-акушерлык пунктының мөдире буларак, әнием моны яхшы аңлый. Авыл халкы аның үз хезмәтеннән ләззәт тоеп яшәвенә соклана, әчкерсезлеге, ягымлылыгы өчен хөрмәт итә. Әниемә күп тапкырлар Мактау грамоталары тапшырылды. Авыл хатын-кызлары аны хатын-кызлар советы председателе итеп тә сайлаганнар.

Моннан ике ел элек әтиебез вафат булды. Без дүрт бала калдык. Әниебез безне әйбәт тәрбияләп кеше итәргә тырыша.

Мин дә әнием юлын сайладым, Сибай медицина училищесының икенче курсында укыйм. Теләгем — фельдшер булу. Энем Рәис 6 нчы класста, игезәк сеңелләрем Гөлнара һәм Динара 4 нче класста укыйлар. Дүртебезнең дә әниебезгә гел шатлыклар гына ишеттерәсебез килә. Безгә биргән тәрбиясенә каршы гел яхшылык белән җавап бирсәк иде, дибез.

Әлфия ЮНЫСОВА.
Башкортстан, Баймак районы, Ишбирде авылы.

ӨЛГЕР КЫЗ

Рәисә йокысыннан бик иртә уянды. Югыйсә, эшләгән эшләрне һәм бик соң ятуын истә тотып, соңрак кузгалырга да мөмкин булыр иде. Кичә клубта авылдашлары ул оештырган концертны да бик ошаттылар. Колхозчылар комсомоллар белән берлектә Рәисә чыгарган «Ракета» стена газетасын да яратып карадылар.

Хәер, бу кызның эшләгән эшләрен ошатмаска, өлгерлегенә сокланмаска мөмкинмени?

Ул Кама Тамагы районы, Балчыклы авылында клуб мөдире булып эшли. Үз эшен бик тә яратып башкара Рәисә Ваһаветдинова. Еш кына терлекчеләр, игенчеләр янында була. Аларны яңалыклар белән таныштыра, лекцияләр укый. Картларның, авыруларның хәлен белергә дә, агитколлективка җитәкчелек итәргә дә, читтән торып Буа ветеринария техникумында белемен күтәрергә дә өлгерә. Авылдашлары аны авыл Советына депутат итеп сайладылар.

Юбилей елы өлгер кыз өчен аеруча шатлыклы — аны Коммунистлар партиясенә член итеп кабул иттеләр.

Ә. ХИСМӘТУЛЛИН.

РӘХИМ ИТЕГЕЗ!



Казанда үзәк проспектлардан саналган Татарстан урамында яңа китап кибете ачылды. Әдәбият сөючеләр аны беренче көннән үк үз иттеләр. Бу рәсемдә сез татар әдәбияты бүлегендә эшләүче ягымлы сатучы Фәүзия Шафикованы эш вакытында күрәсез.

Р. ЯКУПОВ фотосы.

ТУГАН ЯКЛАРЫН ОНЫТМЫЙЛАР

Арча районы, Яңа Кенәр авылында кичләрен яшьләрнең күңелле ял итүенә һәркем сокланырлык. Бу хәзер Комсомол урамы дип аталган элекке Ишбай урамы яшьләре инде. Яшьләр аны хәзер дә безнең Ишбай дип йөртәләр. Ул авылның иң очында. Бик зур булмаса да матур урам. Су буенда таллыклар, болыннар күп.

Ял кичләрендә Ишбай болыннарында җыр, бию тавышлары яңгырап тора. Кызлар, егетләр барыбыз бергә җыелып күңел ачабыз. Кайсыларыбыз Казанда эшләп укыйлар. Алар да үзләренең туган якларын онытмыйлар. Бәйрәмнәрне, дусларыбызның туган көннәрен бергә уздырабыз. Укуда да, эштә дә бер-беребезгә булышабыз.

Менә быел безнең арадан Гөлсинә Бәйрәмова, Рәис Фәйзрахманов, Фәридә Мифтаховалар техникумнарын уңышлы тәмамладылар. Фоат Фазылҗанов белән Зәфәр Фатыйховлар әле техникумда укыйлар.

Без, Ишбай яшьләре, киләчәктә дә сынатмабыз. Намуслы хезмәт итеп бер-беребезне онытмый туганнарча яшәрбез.

Мәсхүт ФАТЫЙХОВ.

БӘХЕТЛЕ КЕШЕ

— Иң изге, иң әйбәт хатын ул безнең Саимә, — диләр аның турында Әгерҗе төзелеш материаллары заводының кирпеч сугу цехы эшчәннәре.

Әйе, тыйнак, сабыр, якын киңәшче була белүче, тырышлыгы белән яшьләргә һәрвакыт үрнәк ул Саимә апа Кәримова.

Менә егерме дүрт ел инде кызу мичтән кирпечләр чыгара. Саимә апа бригадасы ел саен яңа рекордлар куя. Ул үзенең хезмәте турында бик гади итеп, мин тормышның мәгънәсен хезмәттән генә табам, ди.

Саимә апа Кәримова коммунистик хезмәт ударнигы дигән мактаулы исемне йөртә, әледән-әле грамоталар, кыйммәтле бүләкләр алып тора. Аның күкрәгендә «Социалистик ярышта җиңүче» значоклары, В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән бирелгән юбилей медале һәм Хезмәт Кызыл Байрагы ордены бизи. Рәсеме — заводның Мактау тактасында, ә исеме КПССның Әгерҗе райкомы Почет китабына кертелде.

Саимә апабыз бәхетле кеше. Хезмәтеннән ямь табып, илебезнең иминлегенә куанып яши ул.

Х. БУЛАТОВ.

ОНЫТЫЛМАС СЛЕТ

Ул көнне Казанның Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасы чәчәкләр кочаклаган, бәйрәмчә киенгән хатын-кызлар белән гөр килеп торды. Хатын-кызларның Бөек Октябрьның алтмыш еллыгына багышланган өченче слетына калабызның иң алдынгы хатын-кызлары җыйналды. Алар арасында кемнәр генә юк: Октябрь революциясе ветераннары, Гражданнар сугышы батырлары, Бөек Ватан сугышы геройлары, бишьеллык ударниклары, партия, совет органнары, фәнни һәм иҗади оешмалар вәкилләре, врачлар, инженерлар, укытучылар... Күпләрнең түшләрен орденнар, медальләр бизи. Залда тантаналы музыка яңгырый.

Слетны КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова ачты. Слетта катнашучыларга тәбрик сүзе белән Казан шәһәр комитетының беренче секретаре Р. М. Мусин чыкты. Трибунага бербер артлы калабызның күренекле хатын-кызлары күтәрелә башлады. Совет хатын-кызлары комитеты члены, медицина институты кафедрасы мөдире, профессор Зәйнәп Якупова, Гражданнар сугышында катнашкан, атаклы Азин дивизиясе сугышчысы, озак еллар мәктәп директоры булып эшләгән орденлы Мәрьям Зәйнуллина, монтажчы, КПССның Үзәк ревизия комиссиясе члены, партиябезнең XXIV, XXV съездлары делегаты, Татарстан Верховный Советы депутаты Г. П. Лоцманова, филология фәннәре докторы, профессор Диләрә Тумашева һәм башка иптәшләрнең чыгышлары көчле алкышларга күмелде. Сүзләр, теләкләр уртак. Кайберләре Октябрь революциясенең җиңүе өчен кулларына корал алып көрәшкән. Икенчеләре — Октябрь яшьтәше, Октябрь казанышларын яклаучылар. Утны-суны кичкән, бәхетле язмыш ялаган ир йөрәкле хатын-кызлар барысы да бердәм рәвештә Илгә, Ватанга тугрылыклы булулары турында сөйләделәр. Шәфкать туташымедсестра, күкрәгендә унбиш хөкүмәт бүләге балкыткан Фәния Чанышева, моннан илле ел элек тракторга утырган беренче механизаторларыбызның берсе булган Хәлимә Гайнуллина, аларның эстафетасын кабул иткән комсомолка «Теплоконтроль» заводы контролеры Кәүсәрия Шәрифҗанова һәм башка йөзләгән хатын-кызларыбыз да биредә үзләренең әнә шул иң изге теләкләрен белдерделәр. Орденлы Татарстанның башкаласы Казанда узган бу слет тарихта үзенең лаеклы урынын алыр.



Слетта очрашкан хезмәт һәм сугыш ветераннары Зәкия Редкозубова (сулдан уңга), Гайшә Гыймранова һәм Евдския Борботконың үзара сөйләшер сүзләре күп.

Р. ЯКУПОВ фотолары.



ОКТЯБРЬ КЫЗЫ

Илдә революция дулкыннары кузгалган вакытта, Яңа Кәшер авылы кызы Рәкыя Ишмиевага әле 13 кенә яшь тулып килә. Шул кадәр яшь булуына да карамастан, кыз Кызыл Армиягә языла һәм ир-егетләр белән бер сафта совет властен яклап, революция дошманнарына каршы сугыша башлый.

Рәкыянең бу адымы үзе үк татар хатын-кызлары өчен зур бер үрнәк була. Авылларда яңа тормышны ныгыту өчен исә мондый үрнәкләр бик кирәк чак, хатын-кызларның активлыгы, көрәшкә кушылуы аеруча мөһим еллар. Рәкыя 1917 елдан башлап 1922 елга кадәр сугышчылар арасында йөри, ак чехларга, колчакчыларга, дутовчыларга каршы көрәшләрдә катнаша. Ул отрядтагы үзе кебек яшь малай белән бергә, авылданавылга йөреп, дошман гаскәрләре турында белешмәләр җыя. Балашов, Воронеж шәһәрләрен ак гвардиячеләрдән азат итүдә Рәкыянең дә өлеше керә. Аннан соң бәрелешләр Себер ягына күчә.

1921 елда Рәкыя Барнаулда була. Ул анда госпитальдәге яралыларга хезмәт күрсәтә, 1922 елда Томскига кайта.

1927 елдан бирле Рәкыя ханым Ишмиева-Кашапова Үзбәкстанда яши. Совет иле ирешкән уңышларга ул ихластан шат. Үзе кичергән шаулы еллар турында яшьләргә бик еш сөйли, авырлыклар белән ирешелгән беренче матурлыкны сакларга, кадерен белеп яшәргә чакыра ул.


ТАШКЕНТ. К. ШӘМСИ.

Күптән түгел Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры К. Гольдониның «Хатыннар гайбәте» пьесасын сәхнәләштерде. Режиссер — Ришат Хаҗиәхмәтов, рәссам — Әхәт Закиров.




Кеккина (артистка Алсу Гайнуллина) белән Беатриче (Татарстанның атказанган артисткасы Асия Галиева).

М. ШАКИРҖАНОВ фотолары.



БӘХЕТЛЕ БАЛАЧАК



ӘСРАР ШАКИРҖАНОВ — республикабызның иң актив фотохәбәрчеләреннән берсе. Замандашларыбызның ул төшергән портретлары, фотоэтюдлар, фоторепортажлар үзәк матбугатта да, Татарстанда чыга торган газета-журналларда да еш басыла. Аның фоторәсемнәре КамАЗ төзелешенә багышланган китапларда, Татарстанга багышланган фотоальбомнарда да чыкты. Казанда, Әлмәттә, Түбән Кама һәм Лениногорск шәһәрләрендә аның фотокүргәзмәләре оештырыла. Без сезгә тынгысыз журналистның шул күргәзмәләргә куелган берничә рәсемен тәкъдим итәбез. Алар балалар дөньясын тасвирлый.

Ромашкалар.

Әтием орденнары.



Игезәкләр.



Беренче сентябрь.

Нәниләргә укыгыз

Роберт МИҢНУЛЛИН

АЛМА БАБАЙ АЛМАСЫ

1

Алма бабай алмагачы
Ай-яй бигрәк алмалы.
Урамга ук чыгып тора —
Үзе кенә алмалы.

Берсе әнә бигрәк пешкән —
Кызыл гына, ал гына.
Сизеп торам, эче тулы
Ширбәт кенә, бал гына.

Шунсын гына — берсен генә
Өзсәң дә ярый кебек.
Ул кызыл алма үзе дә
Гел миңа карый кебек.

Узган саен карап узам —
Исән икән, исән, дим.
Бүген тими торыйм әле,
Я үпкәләр тисәм, дим.

2

Тик бер көнне исем китте —
Җилләр искән алмадан.
Ичмасам авыз итәргә
Яртысы да калмаган.

Бабай бүген бакчасына
Кермәсә ярар иде.
Шул алмасын миннән генә
Күрмәсә ярар иде.

Соң бик кызыккан булсам да,
Мин аңа тимәс идем.
Тиярлек булсам, ялганлап,
Мин алай димәс идем.

Нигә ялганлап торыйм ди,
Түгел бит мин ялганчы...
Башкалары пешсен иде
Бабай сизеп калганчы.

3

Өйгә керсәм, Алма бабай
Мине көтеп утыра.
Чәй янында яныл-пешеп
Мине «тетеп» утыра.

Миннән күзен алмый үзе,
Сине озак көттем, ди.
Җиде чынаяк чәй эчеп,
Тәмам тирләп беттем, ди.

Синең алма ятканны
Сизеп калган идем, ди.
Бу кызыл алманы сиңа
Өзеп алган идем, ди.

Җәл дә түгел, дигән була,
Синең кебек малайга.
Түбәм күкка тия язды,
«Рәхмәт» дидем бабайга.

Бабай үзе көлеп кенә
Басып тора каршымда.
Каян белде икән бабай
Уйларымның барсын да?

Ә алмасы шундый тәмле —
Торганы балдан икән.
Әллә кайчан ук кызыгып
Йөрисем калган икән.

ЯЛГЫЗЫҢ КАЛАСЫҢ ЛА...

Луиза ХӘЙРЕТДИНОВА музыкасы

Халисә МӨДӘРРИСОВА сүзләре

Мамык шәлемне ябынып,
Җиңел тун кигән идем.
Чит атларда бураннарда
Адашыйк, дигән идем. Эх!
Утырмадың атларыма,
Очып үттем яныңнан.
Хәзер килеп нигә тоттың
Атларымның ялыннан?

Юлларымда син тагын да,
Туктаргамы, нишләргә?
Китәргәме сине алып
Буран купкан төшләргә? Эх!
Юк, кирәкми, сугам атка,
Ялгызың каласың ла,
Ә мин очам котырынган
Буранкар арасына!

Салмак

Шейк темпында

Ма-мык шә-лем- не я- бы-нып, җи-ңел тун ки-гән и- дем. Чит ат-лар-да бу-ран-нар-да а-да-шыйк, ди-гән и- дем. Эх!

rit.

Тизләтә барып

У-тыр-ма-дың ат-ла-ры-ма, о-чып үт-тем я-ның- нан. Хә-зер ки-леп ни-гә тот-тың ат-ла-рым-ның я-лын- нан?

Тиз

Лә-лә-лә- лә- лә-лә- ләй. лә-лә-лә-ләй, лә-лә-

Шейк темпында

1. лә.

2. лә.

Бик тиз

Ә мин о- чам!

glissando


glissando


Эх!

Надыйр ӘЛМИЕВ рәсеме.

«АЗАТ ХАТЫН» журналының 1978 елгы 1 нче санына кушымта

ЧИГҮ ҮРНӘКЛӘРЕ








Бу үрнәкләрне Свердловск өлкәсенең Әҗәгол авылындагы укучыбыз Рәфисә Низаметдинова тәкъдим итә. Чәчәкләрне итәк очларына, күлмәк түшләренә, кофта җиңнәренә, куртка кесәләре өстенә чигәргә мөмкин.

Хәзер кайбер кызлар чалбар балакларын да чигеп йөри башлады. Рәфисәнең чигү үрнәкләре, бәлки, андыйларга да ошап куяр.

Кофталар


Хатын-кызга кофтаның артыгы булмый. Аларның берсен юбка белән, икенчеләрен чалбар белән, ә кайберсен костюмсыман күлмәк эченнән дә кияләр. Бу өлгеләр соңгы елларда модалы дип саналган кофталар тегү өчен тәкъдим ителә.







жиң


манжет










алтакта





арттакта


















ЧИГҮ ҮРНӘКЛӘРЕ

ЧИГҮ ҮРНӘКЛӘРЕ







Файдалы киңәшләр

БАЛАЛАР УЕНЧЫКЛАРЫН КАЙДА САКЛАРГА!


Бала караваты агач булса, аның астына уенчыклар өчен шкаф ясарга бик җайлы. Фанердан шкаф ясап, аны карават аякларына беркетегез, аста идәнне сөртерлек кенә ара калсын. Аны карават төсенә буйыйсың, ишегенә төсле балалар рәсемнәре ябыштырырга мөмкин. Шундый «саклагычка» кечкенә балалар да үзләренең уенчыкларын тутыра алалар, шуның белән бергә алар тәртипкә дә өйрәнәләр.

ЧИГҮ ҮРНӘКЛӘРЕ

Журналның бу санында, күпсанлы укучылар соравын искә алып, чигү үрнәкләренең төрлесен бирергә булдык. Монда зур-зур ашъяулыклар читенә, мендәр тышларына, кием-салымга, сөлге-тастымалга төшерерлек үрнәкләр бар.

Рәсемнәр ике төсле җеп белән генә чигелә.









БАС ЧАҢГЫГА, ДУСТЫМ!

Тирә-юнь ап-ак. Тын. Җил әсәре дә сизелми. Күк зәпзәңгәр, ул җир өстенә каплап куелган бик нечкә хрусталь гөмбәзне хәтерләтә. Кар йомарламы ыргытсаң, челпәрәмә килеп коелып төшәр сыман. Тик берәү дә аның ватылуын теләми. Хәтта кар да йомарланмый. Кар бүген гадәттәге мамыктай йомшак карга охшамаган. Ул ап-ак йолдызчыклардан гыйбарәт. Йолдызларның төрлесе-төрле яктан кешеләргә елмаялар төсле, һәрберсе үзенчә ялтырап җем-җем килә.

Беренче карашка, чаңгычыларның тирә-юньдәге бу матурлыкта гамьнәре юк кебек. Алар берсеннән-берсе уздырырга тырышып алга ашыгалар. Инде шомарып, тирәнәеп беткән чаңгы юлы урман куеныңдагы тауга илтә. Киләләр-киләләр дә, кар өстендә чыршы ботакларыдай тигез өчпочмаклы эз калдырып, тауга менәләр. Иң биек ноктага җиткәч, тирә-юньдәге матурлыкка хәйран калып, авырлыкларын чаңгы таягына салган килеш бераз тик торалар. Аннары — син күр дә мин күр, аска очалар. Аяк астында кар чыжылдый, йөзне салкынча саф һава агымы иркәли, җан чиксез рәхәтлек кичерә. Очасың, очасың, очасың... Уңда да, сулда да тау башына таба хәрәкәтләнүче чаңгычылар кала бара. Аларның йөзен аермачык хәтерләп тору мөмкин түгел, күңел — күкләрдә. Синең очуыңны барысы да күзәтә, хуплый.

— Алда сикертмә бар, абайла! — ди берсе.

Син, аның сүзләрен ишетсәң дә, ниндидер нәтиҗәләр ясарга кирәген абайлап өлгермисең. Инде тау итәгенә җиттем, менә туктыйм, менә туктыйм дигәндә, сине ниндидер көч кинәт югары чөеп җибәрә. «Эһ» дияргә дә өлгермисең, «дыңк» иттереп күтәреп тә бәрә. Очып барып, кар эченә чумасың. Шул йомшак салкын кар түшәгенә барып төшкәч кенә, бая колагыңа эләккән сүзнең мәгънәсе ачыклана: «Сикертмә!»

Кар бөртекләре тәнеңдәге бөтен күзәнәкләргә үтеп кергән шикелле. Керфекләрең, чәч араларың — бары да карлы. Тән җылысын тоеп, ак йолдызчыклар суга әйләнә башлый, муеныңа беренче тамчы мөлдерәп килеп төшә, арка чокырың буйлап тәгәрәп төшеп китә. «У-у!»

Чаңгычыга аның монысы да рәхәт кенә. Шул кадәр хозурлык кылып көне буе йөр дә бер мәртәбә егылып, карның салкынын да тойма, йомшаклыгында да тәгәрәмә имеш! Алай булмый ул. Кышның бар матурлыгы — карда, карның бар рәхәте — чума-чума шаяруда, аунауда лабаса!

Чаңгычы шулай уйлый. Егылган җиреннән тиз генә тормый ята әле ул. Әйтерсең лә, аның бар максаты шул булган, кыяфәте: «Ниһаять, теләгемә ирештем!» дигән сыман.

Кышның ял көннәрендә атна саен берничә сәгать вакытыңны менә шушындый чаңгычылар арасында тау-урманнар, кар-бураннар иркендә үткәрсәң, күңелгә бетмәс-төкәнмәс дәрт, яшәү көче өстәлә. Сәламәтлек ныгый, чибәрлек арта.

Күп кешеләр чаңгы юлларына хезмәт коллективларындагы дус-ишләре белән бергә чыга. Казанның пальто тегү берләшмәсендә, мәсәлән, тегүче кызлар җомга көн кичтән үк чаңгыга басалар. Фабрикалар урман арасына ясалган җәйге пионер лагерьларының кайбер биналарын чаңгычылар өчен җайлап җиһазлый. Теләгән кеше ике көн буе урманда чаңгы шуа, ял өчен әзерләнгән өйдә, чәй эчеп, рәхәтләнеп, төн куна ала.

КамАЗның кою заводы яшьләре дә Кама буендагы урманнарны чаңгы киеп урыйлар. Монда уены-чыны бергә дигәндәй, алдагы чаңгы ярышларына әзерлек тә үткәрелә. Физкультурачылар комплекс заводлары арасында беренчелекне алу өчен тырышалар. КамАЗ күләм алга чыкканы зона ярышларын, республика күләм уңышларны күздә тота.

Без журнал укучылар алдына мондый ук бурычлар да куймыйбыз, бөтен кешенең разрядлы спортчы, ярышта беренчелекне алган чаңгычы булуы һич мәҗбүри түгел. Игътибарны шуңа юнәлтәсе килә: ял итүне бер тәртипкә салуда, җанга сихәт алуда чаңгы — алыштыргысыз чара. Кышны ни кадәр генә озын дисәк тә, озаклап уйларга вакыт тараеп бара. Киңәшебез шул, бер-ике сәгать буш вакытыгыз табылса, чаңгы киеп, кырларга, урманнарга ашыгыгыз. Кышның бөтен хәзинәсе — сезнең карамакта!

К. ГАНИЕВА.

ФӘТХИ БУРНАШ ТУРЫНДА БЕР ИСТӘЛЕК



Үткәннәргә борылып карасаң, исең китәрлек: кай арада узган бу гомер! Фәтхи Бурнашның тууына да сиксән ел тулган. Әгәр исән булса, ул үзенең зур бәйрәме көнендә, зур залның сәхнәсендә, чәчәкләр куелган өстәл артында, үзен котларга килгән халыкка карап, куанып утырыр иде. Ни төсле булыр иде икән ул олыгайгач, сиксәнгә җиткәч!

Мин сиксән яшьлек Фәтхине күз алдына китерергә тырышып карыйм, ләкин булдыра алмыйм. Хәтта кырык яшьлек Фәтхи дә сирәк күз алдына килә. Мин аны һәрчак унсигездә итеп хәтерлим. Чөнки аның белән дуслыгым шул чакта башланды, аңа булган ихтирамым, яратуым яшьлектә туды.

Без аның белән Казандагы Мөхәммәдия мәдрәсәсендә бер чорда укыдык. Дөрес, Фәтхи югары сыйныфта укый иде, шунлыктан ул чакта без аның белән ныклап аралашып китә алмадык. Без Фәтхинең энесе Вафа белән бер бүлмәдә яши идек. Хәтерлим: Вафа бик матур җырлый иде һәм җырларга бик ярата иде. Фәтхине мин Вафа янына кергәндә генә күрә идем.

1916 елны Фәтхи мәдрәсәдә күренмәде, читтә торып русча укып йөргән икән. Җәен мин авылга китмәдем, Казанда яшәдем. Ул чакта Болгар номерлары белән янәшә бер йортның флигелендә учительская школада укучы яшьләр тора иде. Хәтерлим: алар арасында Чанышев та бар иде. Флигель тирәсе бик җанлы була, уен-җыр, шаярыш; әдәбият, киләчәк турында бәхәсләрдән шаулап тора, шунлыктан мин дә анда бик еш була идем.

Фәтхи белән без шул чакта дуслаштык. Дуслыкның нидән башланганын хәзер анык кына әйтә алмыйм, миңа аның белән рәхәт иде, күңелле иде. Ул чакта инде минем шигырьләрем матбугатта чыга башлаган иде, күрәсең, минем иҗатым Фәтхигә ошагандыр.

Җәйге кичләрдә без өчәү — Фәтхи, мин һәм бер ишкәкче егетебез — Кабан күленә чыга торган идек. Көймәгә утырабыз, ишкәкчебез кулына бирәр казык яисә такта кисәге табып ала иде дә, без йөзеп китә идек. Күл уртасына җиткәч, туктыйбыз. Фәтхи, кулына мандолина алып, җыр башлый. Ай яктысында ялтырап яткан су өстеннән көчле сихри моң тарала. «Әллүки»... Бигрәк матур, көчле, моңлы иде Фәтхинең тавышы, аны тыңлаган саен тыңлыйсы килә иде. Кайчак мандолинаны мин чиртәм, Фәтхи җырлый, без аңа кушылабыз. Бөтен шәһәр тынып безне тыңлый шикелле.

Аннары без Кабанның аръягына, «Аркадия» бакчасы (хәзерге зоопарк) янына барып, су коенабыз. Ә кайтканда әдәбият, сәнгать, философия турында чын күңелдән сөйләшү була. Хәтеремдә, ишкәкче егетебез бик каты шекспирчы иде. Ул һәрвакыт аның трагедияләреннән мисаллар китерә, татар драматургиясе дә Шекспир планында дөньякүләм каһарманнар торгызу юлында үсәргә тиеш, дип сөйли иде.

Фәтхи бәхәсләшкәндә алай нык кызмый, аз сөйли, ләкин бу хакта аның да нык уйланганы сизелә иде.

Озак та үтмәде, ул «Таһир-Зөһрә» трагедиясен һәм «Яшь йөрәкләр» драмасын иҗат итте. Күрәсең, аның күңелендә бу әсәрләргә нигез без очрашып йөргән чакларда ук салынгандыр. Фәтхинең күңелендә ниләр кайнаганын ул чакта мин аңлап җиткермәгәнмен, аларны мин бары тик соңрак кына чамалый башладым.

Көзен мин авылга кайтып киттем һәм яңадан Казанга килмәдем. Ул чакта «Аң» журналында минем шигырьләрем, поэмаларым басылып тора, редакция бу журналны миңа авылга да җибәрә иде. Бер заман журналның унынчы санын алып карасам, ни күзем белән күрим, «Дулкыннар арасында» дигән зур бер поэма. Ахырында авторның исеме — Ф. Бурнаш. Поэманы укып карыйм: бик шәп, бик оста каләм белән язылган, миңа бик ошады. Аңарчы мин Фәтхинең шул хәтле шәп романтик шагыйрь икәнлеген белми идем әле. Күрәсең, бу — Фәтхинең тыйнаклыгы аркасында килеп чыккандыр.

Шуннан соң без Фәтхи белән шактый озак еллар күрешмәдек, ләкин ул дуслыкка гаҗәп тугрылыклы булып чыкты, мине ташламады. 1923 нче елны «Керәш җырлары» исемле җыентыгын чыгарды һәм шунда хат язып минем шигырьләремне сорап алды да, җыентыгында бер бүлек ачып, аларны басып чыгарды.

Әмма бу чор эчендә ул мине онытса да бер дә гаҗәп булмас иде: ул елларда Фәтхинең башыннан ниләр генә үтмәде!

Ул 1919 елда партиягә кергән, Октябрьның беренче көннәреннән үк зур иҗтимагый һәм әдәби эшчәнлеген башлады. Гражданнар сугышы вакытында аклар кулына эләгә, аны «үлем эшелоны»на утыртып җибәрәләр. Бәхеткә каршы, Фәтхи аннан качып котыла, аклар тылы аша озын юл үтеп, фронтны кичеп, кызыллар ягына чыга.

Соңыннан Фәтхи Бурнаш «Кызыл Татарстан», «Безнең юл», «Кызыл дәфтәр» газеталарының һәм «Чаян» журналының редакторы булып эшләде. Шул ук вакытта иҗат эшен дә һич туктатып тормады. Фәтхи Бурнаш — утыз поэма, йөз илледән артык шигырь, егермедән артык пьеса, опера өчен биш либретто һәм өч йөздән артык ялкынлы публицистик мәкалә язган.

Ул бик күп һәм тиз яза, гаҗәп актив эшли иде. Ул татар әдәбиятында поэма жанрын бик нык күтәрде. Аның «Куркут» дигән поэмасы турында академик Петр Коганның бик әһәмиятле, матур фикерләре бар. Мин аның поэмаларын әле дә кайта-кайта яратып укыйм. Аларда хәзерге заман шагыйрьләре өчен дә өйрәнелергә тиешле файдалы алымнар бар.

Аның «Таһир-Зөһрә», «Яшь йөрәкләр», «Лачыннар» һ. б. сәхнә әсәрләре татар драматургиясенең шедеврларыннан саналырга хаклы. Алар яңадан-яңа режиссерларга һәм артистларга иҗат өчен киң мәйдан булып торыр һәм күп буын тамашачыларының күңелен тетрәтер әле.

Билгеле, Фәтхи Бурнашның иҗаты бик киң колачлы, катлаулы һәм зур күләмле.

Минемчә, Фәтхи Бурнашның иҗаты әлегә тулысы белән өйрәнелеп бетмәгән һәм әсәрләре дөньяга тулысы белән чыкканы юк. Аның әдәби мирасы олы һәм әһәмиятле, ул ныклап өйрәнелергә тиеш.

Минем күңелемдә исә ул олы шагыйрь, драматург, әдәбиятыбызның зур вәкиле буларак кына түгел, эчкерсез, киң күңелле, юмарт табигатьле, мәхәббәт кеше буларак та саклана. Исән булса, ул мине бүген дә елмаеп каршы алыр, тәмле итеп табада бәрәңге кыздырып ашатыр иде — без Казанда очрашканда гадәттә шулай була иде бит.

Ул картаерга өлгермәде, бишенче дистәне ваклагач, безнең арабыздан китте. Әмма, исән булса, бүген дә карт күренмәс, һаман шулай яшь, хәрәкәтчән, сөйкемле булыр иде ул. Һәм әдәбиятыбызны үзенең иҗаты белән әлбәттә тагын да ныграк баеткан булыр иде.

Тормышта да, әдәбият эшчәнлегендә дә безнең барыбыз өчен дә гүзәл үрнәк иде ул — минем яшьлек дустым Фәтхи.

Нәкый ИСӘНБӘТ.

Язучы Аяз Гыйләҗев безнең укучыларга яхшы таныш. Әле илленче елларда ук аның хикәяләре, юморескалары, фельетоннары, зур проблемаларны эченә алган публицистикасы «Азат хатын» журналында еш басыла иде. Гаҗәп тә түгел: ул чакта Аяз Гыйләҗев редакциянең үзендә әдәби хезмәткәр булып эшләде. Озак та үтмәде, язучының зур күләмле әсәрләре дөнья күрә башлады. Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры аның «Җиз кыңгырау» драмасын сәхнәләштерде. Нәшриятта язучының китаплары чыкты. «Берәү», «Өч аршин җир» кебек повестьлар дөнья күрде. Аларны рус теленә дә тәрҗемә иттеләр. «Өч аршин җир» исемле повесть өчен аңа «Дружба народов» журналының бүләге дә бирелде.

Быел гыйнвар аенда Аяз Гыйләҗевка илле тула. Язучы үзенең бу юбилеен гаҗәеп мул иҗади уңыш белән каршылый. Беренче китаплары чыга башлаганга әле егерме ел да вакыт үтмәгән, ә укучы аның романын да, уннан артык повестен да, иллегә якын хикәяләрен дә укып белә.

Татарстан, Башкортстан, Чувашстан, авар, рус театрлары сәхнәләрендә Аяз Гыйләҗевның егермедән артык пьесасы куелган. Тамашачы аның «Көзге ачы җилләрдә», «Киек каз юлы», «Кар астында кайнар чишмә» пьесалары буенча куелган спектакльләрне аеруча хуп күрде.



Язучының иҗади активлыгы җәмәгать эшләрендәге өлгерлеге белән тыгыз элемтәдә үсә. Аяз Гыйләҗев Татарстан Язучылар союзындагы драматурглар секциясен җитәкли, яшь язучыларга файдалы киңәшләр белән ярдәм итә, вакытлы матбугатта чыгышлар ясый.

Үзенең илле еллыгына язучы «Без унике кыз идек» исемле яңа пьеса язып өлгертте. Әсәр хатын-кызларның үзара мөнәсәбәтен күрсәтүгә багышланып, анда дуслыкка тугрылык, иптәшләргә вакытында ярдәм итәргә кирәклек, аларны игътибардан читләштерергә ярамау хакында җитди сүз бара. Пьесаның бер күренешен укучылар игътибарына тәкъдим итәбез, ә тулаем аны тиздән Әлмәт театры сәхнәсендә карарга мөмкин булачак.

Илле еллыгы уңаеннан без язучыны кайнар котлыйбыз, аңа нык сәламәтлек, иҗади уңышлар, бәхет телибез.

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

БЕЗ УНИКЕ КЫЗ ИДЕК

ДРАМАДАН ӨЗЕК

Катнашалар:

ЗИЛӘ — артистка
НАИЛӘ — секретарь-машинистка

ЗИЛӘ. Театрда ял көне иде. Дүшәмбе. Ирем дә ялда чак туры килде. Кисловодскига озаткан идем аны. Япа-ялгызым китап укып ятам шулай, ни укыганымны да белмим, әллә китабым күңелсез, әллә көне ямьсез, шомланып та куям. Тышта җил, чамасыз! Басынкы гына килеп керде ул.

(Зилә сөйләгәндә Наилә керә һәм ул сөйләгәннәрне эшли.)

Чишенде. «Торма, торма, бик тәмле ятасың, кырыңда утырып кына торам», диде. Шунда мин туп-туры аның күзләренә карыйм. Абау, күзләре ут булып яна, битләре алланган, бөтен кыяфәтендә наз, иркәлек, бер үк вакытта көчле рух аңкый иде.

(Диванга барып ята, китап ала, Наилә аның янына килеп утыра.)

НАИЛӘ. Торма, торма, зинһар. Кырыңда гына утырып торам. Бигрәк тәмле итеп ятасың.

ЗИЛӘ. Әй, болай уңайсыз. **(Тора, Наилә белән кочаклашып утыралар.)**

НАИЛӘ. Нихәлләрең бар, Зиләйлүк?

ЗИЛӘ. Һәммәсе әйбәт. Гомер генә уза.

НАИЛӘ. Шуны сизә аласыңмы?

ЗИЛӘ. Сизмичә. Актерның бәхетсезлеге шунда, ул ярты гомерен көзге каршысында, икенче яртысын халык күз алдында үткәрә. Теләсәң-теләмәсәң дә һәркөн барлык җыерчыкларыңны санап чыгасың. Арталар! Үзеңдә ниләр?

НАИЛӘ. Дөнья матур, Зиләйлүк.

ЗИЛӘ. Шуны исбатлый аласыңмы?

НАИЛӘ. Исбатлыйм.

ЗИЛӘ. Көтәм.

НАИЛӘ. Мин сиңа тагын бер яңа җыр алып килдем. Яңа дип, иске җыр ул, борынгы җыр, Болгардан ук калмадымы икән?

ЗИЛӘ. Элегрәк ел саен җыр белән куандыра идең. Һәр җырың күңелеңнең серен ача торган иде. Бүген нинди сер китерде икән сине минем катыма?

НАИЛӘ. Җыры барның — сере бар. Минем моңарчы ул җырны ишеткәнем юк иде. Аны миңа бер кеше җырлады... Җырчы түгел, гап-гади кеше. Әмма гаҗәеп кызыклы, акыллы, тирән фикер иясе кеше. Тормышны яратучы бай рухлы кеше. Җырлап күрсәтимме?

ЗИЛӘ. Җырла.

НАИЛӘ. Миңа җырлаган кеше аны «Ләке авылы көе» дип атады.

ЗИЛӘ. Ул шул авылныкымы?

НАИЛӘ. Түгел. Шул якта туган гына. Тыңла.

Олы юлга чыккан идем
Чакрым саен багана.
Әллә теләп, әллә болай
Рәхәт килде замана.
Әйдә, әйдә! Кая, кая?
Әйдә барыйк урманга.
Урман буйлары абага,
Урман суы шәп ага.
Сөймик икәү бер чибәрне,
Әйдә салыйк шобага!

Олы юлга чыккан идем
Чакрым саен багана.
Әллә теләп, әллә болай
Авыр килде замана.
Әйдә, әйдә! Кая, кая?
Әйдә барыйк урманга.
Урман буйлары абага,
Урман суы шәп ага.
Сөймик икәү бер чибәрне,
Әйдә салыйк шобага!

ЗИЛӘ. Искиткеч җыр! Аерата кушымтасы төгәл эшләнгән. Тик бер ягы сәер — башта замана рәхәт килде дип җырлана да, азагы күңелсез бетә.

НАИЛӘ. Мин дә аннан сорадым шуны!

ЗИЛӘ. Аңлаттымы?

НАИЛӘ. Җырны кем генә җырламый аны, диде. Рәхәттә дә, михнәттә дә җыр юлдаш... Әллә дөньяда бар кеше рәхәткә чыккан дип уйлыйсыңмы, диде.

ЗИЛӘ. Әйдә, әйдә! Кая, кая?

Әйдә барыйк урманга.
Урман буйлары абага,
Урман суы шәп ага!

НАИЛӘ. Уйлап караганың бармы, Зиләйлүк, безнең арабызда иң бәхетлесе син бит?

ЗИЛӘ. Көнләшәсеңме?

НАИЛӘ. Сиңа нигә икәнен дә аңлатып бирергәме?

ЗИЛӘ. Минем тормышны ничегрәк күз алдына китерәсең икән син. Шуннан чыгып, мин синең идеалыңны, кая табарак һәм ниндирәк кешегә омтылуыңны белер идем.

НАИЛӘ. Син бөтен барлыгың белән, җүләрләрчә гашыйк булып кияүгә чыктың. Ике ел буе сөешеп кияүгә бардың. Лаеклы ир сайладың. Асыл иргетне. Җаның теләгән хезмәткә гомереңне багышладың. Ләрия дә артистка булам дип йөргән иде, зарплатасының күпме икәнен белгәч, документларын бик тиз барып алды. Диләрә дә врач булам диде, җиде ел укырга кирәклеген аңлагач, койрыкны сыртка салды. Дөрес, алар да яши, файдалы эштә эшлиләр, мәгәр син генә үз теләгеңә ирештең. Авыр дип тормадың, аена утыз сум түләп чит кеше бусагасында торса-

гыз да лаф ормадыгыз, матур тормыш кордыгыз. Тәнегез генә түгел, рухыгыз да бергә булды. Бергә! Бергәлектән, бер-берегеңне эчкерсез хөрмәт итә белүдән һәм мәхәббәттән олы бәхет бармыни бу дөньяда?

З И Л Ә. Әнә көн дә хат яза, сагынам, ди.

Н А И Л Ә. Сагынуына да ышанырга була аның. Рәхәттер ул шашып сагынышкан чаклар!.. Уйлар тоташ ут булып аккан минутлар!.. Очрашып кочышканда җир тирбәлеп китә торгандыр... Яхшы, тату, дус яшисез, тик шулай да сезнең өйдә җылы юк.

З И Л Ә. Туңасыңмы?

Н А И Л Ә. Синең урында булсаммы мин...

З И Л Ә. Озак югалып торасың да, очрашкач, ятсынып карап торам: кем соң син? Очрашмый торган арада кемгә әверелдең?

Н А И Л Ә. Бала белән тутырыр идем мин бу йортны!

З И Л Ә. Һич көтелмәгән сүз сөйлисең, һәм матур сөйлисең, каһәр суккыры! Белеп сөйләмисең, шунысы кызганыч.

Н А И Л Ә. Бала тавышы яңгырамаган өйдә кот юк. Бу идәннәр гомергә ятим — алардан тупырдап, үкчәләрен ялтыратып бала йөгереп китмәгән. Синең утлы күкрәкләреңә кабарынкы иреннәре белән бәби капланмаган...

З И Л Ә. Җаным, үз балаң булмаганга гына сөйлисең. Баланың мең дә мең мәшәкате, бәла-казасы бар аның. Төн уртасында җылап уяна ул, киреләнә, интектерә, җәфалый, таңнан торып мәми сорый, чүпрәкләрен пычрата. Кызамык сагалый аны, ютәл, томау, свинка, теше авырта аның, колагы котырып сызлый. Борынын идән ярыгына кыстыра ул, бармагын электр розеткасына илтеп тыга. Ботка ашамый, әфлисун даулый. Куйган әйберең урынында түгел, «Нефертити» хушбуен кер юу порошогына бутый ул. Вата, җимерә, ерта, буйый, кыра, пычрата, тарката, урамнан канга батып сугышып керә, кыскасы, татар телендә нинди фигыльләр булса, барын да эшли.

Н А И Л Ә. Сәламәт, семьясы төзек хатынның баласыз калуы җинаять.

З И Л Ә. Кем каршында җинаять?

Н А И Л Ә. Барыннан да элегрәк, үзе каршында.

З И Л Ә. Мин артистка. Көч, егәремне, талантымны халыкка бирергә бурычлы.

Н А И Л Ә. Ни өчен халыкка гына?

З И Л Ә. Сәнгать мәңгелек.

Н А И Л Ә. Әгәр үз кәефебез өчен генә яшәсәк, сәнгатьнең кемгә кирәге калыр? Бозлы атаудагы пингвиннарга күрсәтербезме без аны? Менә сиңа авыл көе ошады. Борынгы көйдер ул! Кемдер саклаган бит аны. Кадерләп күңелендә йөрткән, буыннан-буынга, сөйгән ярларга тапшыра килгән.

З И Л Ә. Син бу көйнең иясенә гашыйк булгансың! Ур-ра!

Н А И Л Ә. Ашыкма, Зилә. Син уйлаганча ук түгел... Бала хакында ни диден инде?

З И Л Ә. Үгетләмә, Наилә.

Н А И Л Ә. Иреңә бала кирәкмиме?

З И Л Ә. Кайсы ирнең эти дигән сүз ишетәсе килмәс. Ул бик тели.

Н А И Л Ә. Син—җинаятьче. Балаң бәлки ирең төсле галим булыр. Бәлки, сиңа охшап, сәнгать юлын сайлар. Ил сакчысы, сугышчы булыр. Бала—мәхәббәтнең иң татлы, иң затлы җимеше. Бала — синең дәвамың. Сөюеңнең юкка булмаганын раслау. Бала—алда син күрмәгәнне күрәчәк. Бала—сине якты киләчәк белән ялгаучы. Бала куаныч. Җан азыгы. Һәр иртәдә балкый торган назлы кояш. Синең бөтен күзәнәкләреңдә тереклек уятучы. Ир белән ике араны ныгыту!

З И Л Ә **(кинәт калкынып)**. Син минем ирем белән хат алышасың! Яки очрашасыз сез!

Н А И Л Ә. Синең ирең белән дә очрашам әле икән мин!

З И Л Ә. Ул котыртып җибәргән сине!

Н А И Л Ә. «Без-без без идек, без уникe кыз идек!» Бу бит балачак, Зилә! Хатын-кыз дуслыгы чуалчык нәрсә. Әле икәүдән-икәү дус булу да читен. Ә син унике хатынны бер учка сыйдырмакчы буласыңмы?..

З И Л Ә. Мин дуслыкка ышанам. Безнең Рабигалар, Айсылулар, Нәҗияләр бер чакта да хыянәт итә торган зат түгел.

Н А И Л Ә. Мин дә ышанам! Тик яхшы чакта бар да яхшы! Тормыш ага... Аның үлеме-җитеме бар дигәндәй, бәласы-казасы...

З И Л Ә. Син бик еракка сикердең. Әле генә бала иде, хәзер кабер?..





Н А И Л Ә. Ул да мине котырта икән әле!

З И Л Ә. Югыйсә аның сүзләрен каян белер идең? Бөтенесе туры килә, җөмләләренә кадәр!.. Син аның белән язышасыңмы? Әйтәм җирле ул гел сине мактый.

Н А И Л Ә. Синең шундый сүзләрне әйтә белә торган фәрештә ирең бармы? Җүләр! Сине үгетләргә килмәдем, юк, юк, хафаланма... Бергә! Син шул сүзнең тирән, газаплы мәгънәсен аңлыйсыңмы? «Сунын кадерен чүлдән килгән юлчылардан сорап бел!» дигәндәй, бергәлекне ялгыз калгач кына бәһалисең аны, Зиләйлүк! Адәм баласының иң куркыныч дошманы—ялгызлык. Таңда да ялгыз, кичен дә ялгыз. Ялгызның караңгысы куерак, шомлырак... Хатын-кыз ялгызлыгы исә тагын да аянычрак!

З И Л Ә. Ялгыз түгел ич син! Ә мин? Ә без?

Н А И Л Ә. Беребез дә мәңгегә килмәгән.

З И Л Ә. Син авырмыйсыңмы?

Н А И Л Ә. Авырмыйм. Бу йөрәк ничек чыдый икән дип гаҗәпләнеп кенә куям.

З И Л Ә. Куркыттың мине.

Н А И Л Ә. Ә син бернидән дә курыкма! Мин сыңар канат килеш курыкмаганны...

З И Л Ә. Минем бәби алып кайтасым килеп китте.

Н А И Л Ә. Чынлапмы?

З И Л Ә. Идәннәрне тупырдатып чабып китәр дисеңме?

Н А И Л Ә. Китәчәк!

З И Л Ә. Шушы бүлмәләрне тутырып бер җылар дисеңме?

Н А И Л Ә. Җылар!

З И Л Ә. Синең сафлыгыңа, батырлыгыңа сокланам!

Н А И Л Ә. Рәхмәт, Зиләйлүк! Синең сүзең бик кадерле миңа!

(Җырлыйлар.)

Б Е Р Г Ә. Әйдә, әйдә! Кая, кая?
Әйдә барыйк урманга.
Урман буйлары абага
Урман суы каты ага.
Сөймик икебез бер ярны,
Әйдә салыйк шобага!..

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

* * *

Очрашканга күпме генә!
Инде йөз ел белешкән күк!
Синең белән бар үткәнне
гел икәүләп бүлешкән күк.

Каян килгән таңгаллек бу —
сулышта да, адымда да.
Синең уең миннән үтә,
минем хисләр синдә ага.

Синең шатлык — минем шатлык,
минем көйләр — синең көең...
Минем белән табышканчы,
кем идең дә кайда идең?
........кайда идең?..

...Без әллә булганбыз микән
бер үләннең яфраклары?
Кеше булып әверелергә
аерылганбызмы аннары?

...Менә тагын аерылабыз.
Юлы кая бу көннәрнең?..
Син дә берни әйтә алмыйсың,
тик дерелди иреннәрең...

Авыл. Кич. Капка төбе

Ятсыныпмы, сагаепмы,
авылдашлар җайлап кына,
сөйләшәләр урап-урап,
сүзләрне бик сайлап кына.

Күренеп тора — ачылмыйлар,
бик чишелеп китәргә юк
исәпләре. Ишетәм гүя:
«Бүген бар син, иртәгә — юк...»

Мин дә артык эчкә кермим,
әйткәннәрен җөпләп торам.
Тышган бер сүз, эчтән һәркем
үз уйларын үзе кора.

Мин дә эчтән үземә әйтәм:
«Туйдырма син, ялыктырма!..»
Тәмәке төтене аша
күрәм — йортлар, яңа урам...

Әнә, бабамнар нигезе...
Хәзер анда кем бурасы?
Агайларның исемен белмим,
«кемнеке?» дип бик сорасы...

Аннан китәм ялгыз. Юлым —
чишмә буе, зират, урам...
Күп торсам Туган нигездә
тагын бер-ике көн торам.

Сау булыгыз, авылдашлар:
мин бит монда кунак кына...
Ял итәргә дулкынына
кунган акчарлак кына...

* * *

Атлыйм көзге урман эченнән.
Дөнья шәрә. Суык. Кыш алды.
...Күп нәрсә ачык хәзер. Юллар аңык.
Хыял томаннары таралды.

Ерактарак, алан өстеннән
нидер очты җил уңаена.
Әллә чыпчык, әллә кипкән яфрак?
Белә алмадым ни булганын да.
Күз шәйләде, күңел күрмәде.
Әллә чыпчык,
әллә кипкән яфрак?..

Әлмәтне сагыну

Бергә чаклар искә төшә,
Әлмәт диеп бер җырласаң.
Синдә генә калыр идем,
Казанкаем, син булмасаң!..

Үз Казаныңда яшисең,
нигә дип сагынасың?
Дегетле Зәе тансыкмы,
әллә газлы һавасы?

Артык данлыйсың түгелме
Илнең гади каласын?
Тәнендә ул як җирләрнең
кырык меңләп ярасы...

Сагынам, сагынам дисең,
тикмәгә түгелдер лә!
Ниндидер бер хикмәтле сер
ятадыр күңелеңдә...

Әлмәттә зур данга лаек
я бер эшең булгандыр?
Я мәңгегә табылмаслык
берәр кешең булгандыр?

Сагынасыңдыр, бәлки, анда
үткән яшьлек елларың?
Я тансыктыр анда язган
ихлас дәртле җырларың?

Бәлки гашыйк калгансыңдыр
факеллы таңнарына?
Бигеш ягы урманының
айлы сукмакларына?..

Сагынам, сагынам дисең,
тикмәгә түгелдер лә,
Шул якка аккан болытлар да
кагыла күңеленә!

. . . .

...Төпченмә, дус, сәбәп-сереңнең
сиңа ни кирәге аның!
Аз да түгел, күп тә түгел,
минеке бар булганы!

Әйтәме кеше, беренче сөюен
ни өчен сагынганын?
Әлмәт дигәч, шуның кебек,
халәте минем җанның.

Тау төшү

Бер утызны узгач
түбән таба —
текә икән гомер тавы!..
Тәгәри таш!

Торган саен моңсулана бара
җәен кошлар тынган чаклар,
айның ындүртләре узган көннәр,
үткән поездларның
борылмада югалулары...

Күзне сагышлатып, әчеттерә күбрәк
кабатланып килгән язларның
битне иркәләүче җилләре...

* * *

Очты, китте Сөю!..
Ак күгәрчен булып очты!
Калды бурыч —
кургаш кебек авыр
кара каурый.



Утрау

Ул кояшлы утрауны Синең өчен эзләп
таптым.
Торсын дидем бер
таҗы булып Табигатьнең
кешеләрсез яшел дөнья уртасында,
үзен алиһәдәй тоеп!
Яшәсен бер дидем онытылып,
җил, дулкыннар белән берлектә!

Синең өчен иде утрау!
Синең өчен иде Вакыт!
Синең өчен идем мин!

...Хәзер утрау дигәч искә төшә —
палатка янындагы гөлҗимешләр,
йокы аралаш ишетелгән пароход
тавышлары,
шыбыр-шыбыр яуган төнге яңгыр,
яртысы да укылмаган калын китап,
Кама ярындагы керашә оялары...
Ә Син — юк...

* * *

Гашыйк бер пар үтте янәшәмнән.
Туктап-туктап шашып үбешәләр!..

Юк, көнләшмим кеше бәхетенә.
Минем дә булды былбыллы чаклар!
Шат авазым күмде күкрәүләрне,
офыкларгача янды учаклар!

Бәлки, ул чаклар туры килгәннәрдер
кара көннәренә кемнәрнеңдер?..
Мин, сөюдән исереп, бу дөньяны
гел ал да гөл диеп йөргәнмендер.

...Менә бүген миңа килеп тиде
кара кайгының канлы канаты.
Янам эчтән, үксим... әллә нишлим —
шушы була микән инде җан ату?

...Алар бара. Көлә, шаяралар!
Шулай кирәк — иңдә бәхет барда!
Озаграк торсын сездә бәхет кошы,
миңа кунган чакка караганда!

УЙНАУЧЫ ДА, ҖЫРЧЫ ДА



— Күрдеңме, теге артистка узып китте. Кем әле! Кичә академия театрында Рәйсәне уйнады. «Әнә килә автомобиль»дә... Ничек соң әле фамилиясе!

— Рауза Хәйретдиновамы! Ул бит Галиябануны уйный иде...

Сәхнә осталары белән якыннан кызыксынучылар күп. Әлеге кызлар да шундыйлардыр. Бәхәсчеләр арасына кермик. Безгә исә аңлашыла, икесе дә бер үк артистка турында сөйлиләр. Шунысы игътибарга лаек: кайда гына күренмәсен, нинди генә киемдә булмасын, театр сөюче халык Рауза Хәйретдинованы тиз таный. Кыюраклары «син шул артистка бит» дип, килеп күрешүдән дә тартынмыйлар, кайберәүләреннән бәйрәм саен котлаулар килеп тора.

Менә бер хат.

«Хөрмәтле Рауза Котдусовна! Мин күп еллар дәверендә сезнең Татар академия театры сәхнәсендә хатын-кыз рольләрен уңышлы башкаруыгызны карап киләм. Театрдан кайткан саен сезнең искиткеч табигый итеп уйнавыгызны сокланып, иҗатыгызда һаман алга баруыгыз өчен шатланам. Мин сезне театрыбызның 70 еллык юбилее уңае белән тәбриклим. Сезгә сәламәтлек, тормышыгызда тигезлек, иҗади уңышлар һәм зур бәхет телим.

Ихтирам белән, Рәшидә ПАТУХИНА, Казан медицина институты ассистенты».

Рауза Хәйретдинованың бөтен аңлы тормышы театр белән бәйләнгән. Бу табигый сәләт аңа бәлки гармунчы әтисеннән, бәлки җырчы әнисеннән күчкәндер. Әмма Раузаның яшүсмер вакытында авыл сәхнәсендә уйнаган беренче Галиябану роле аның иҗади сәләтенең саф чишмәдәй ургый башлавы булган. Иҗади хезмәттә, аңа үзеңне тулысынча багышлаганда гына җитди уңышка ирешүең мөмкин. Мин Рауза Хәйретдинованың иҗади үсеш юлын 1948 елдан бирле игътибар белән күзәтеп киләм. Аның театр сәхнәсенә аяк басуына, Татар дәүләт академия театры каршындагы студиядә укыган ике елны да кертеп исәпләсәң, утыз ел тула. Шушы еллар эчендә ул тудырган образларны санап кына чыгу өчен дә шактый вакыт кирәк булыр иде. Эпизодларын кертеп тормыйча да мин аларны 75 кә чыгардым.

Шул кадәр образ тудырылган. Образны һәркем үзенчә тасвирлый, аның кичерешләрен үз йөрәге аша уздыра, үзе генә белгән, үзе генә тапкан сәнгатьчә бизәкләр белән баета.

Илленче еллар башыннан алып ун елга якын Академия театры сәхнәсендә Галиябану-Рауза балкыды. Саф мәхәббәт үрнәге булган Галиябану-Раузаның килешле уены, йөрәкне өздереп җырлавы тамашачы күңеленә онытылмаслык булып кереп калды. «Зәңгәр шәл»дәге Мәйсәрә сәхнәдә унбиш ел буе Рауза Хәйретдинова таланты белән яшәде.

Ниндиләре генә булмаган ул рольләрнең! Классик әсәрләр, революцион спектакльләр, хәзерге чор драмалары... «Татар хатыны ниләр күрми» (Гөлбану), «Миркәй белән Айсылу» (Айсылу), «Казан сөлгесе» (Мөршидә), «Ташкыннар» (Гөлчирә), «Таң атканда» (Гөлбикә) һәм башка бик күп әсәрләрдә ул баш рольләрне халык күңеленә барып җитәрлек ышандыру көче һәм тирән кичерешләр белән уйнады. Без һаман «уен» дип сөйләргә яратабыз. Ә бит Раузаның үз сүзләре белән әйтсәк, «сәхнәдә уйнау—уен эш түгел. Ул талантың булу өстенә тырышлык, иҗади эзләнү, өйрәнү, өлкән буын сәхнә осталарының традицияләрен тагын да тирәнәйтү, заманга ярашлы итеп дәвам итү, үстерү». Бу сүзләргә өстәп Рауза Хәйретдинованың шушы изге максатка баштанаяк тугры булып баруын, тормышчан образлар тудыруын әйтәсе килә.

Рауза Хәйретдинова өлешенә төшкән тагын бер җитди һәм авыр бер иҗади йөк турында әйткән идек. Ул — җырлаучы рольләр. Татар тамашачысы үзенең яраткан баш театрын җырмузыкасыз күз алдына да китерми. Театрга җырчылар да, биючеләр дә, гармунчылар да бик кирәк. Рауза әнә шул ихтыяҗга җавап бирә. Драма уены һәм җыр Рауза иҗатында гармоник рәвештә бәйләнгәннәр.

Сәхнәдә бер үк вакытта уйнау һәм җырлау гаять катлаулы, үзенә бер аерым сәләткә ия булуны сорый. «Зәңгәр шәл»дә унбиш ел эчендә Мәйсәрә-Рауза алдында дүрт Булат уйнады, ягъни дүрт артист алышынды. Ә Рауза һаман уйнады, җырлады. Саф музыкаль тавыш сәләте аңа тумыштан бирелгән. Режиссерлар, җырлы әсәрне сәхнәгә куярга җыенганда, шундый рольләрне гел Раузага тапшырдылар. Рауза әсәрдәге образны җыр белән тиешле югарылыкка күтәрсә, образ артистканың үзен яңа иҗади биеклеккә күтәрә барган. Кайсы гына ролен алып карама, Раузаны актриса буларак тамашачы тарафыннан яраттырган, гөр килеп кул чаптырган, ямансулаткан һәм дәрт биргән әнә шул җыр булгандыр, мөгаен.

Спектакль саен яңа характер ача Рауза. Һәркайсы—иҗади уңыш, алкышлар. Яңа рольләрдә Рауза Хәйретдинова иҗаты тамашачыга бөтенләй икенче ягы белән ачыла бара. Клеопатра («Дошманнар»), Дибәҗә («Көзге ачы җилләрдә»), Сәрби («Һиҗрәт»), Мәрвәр («Зөбәйдә — адәм баласы»), Рәсиха («Әни килде»), Кәримә («Ике буйдак»)—санап бетергесез ул тудырган характерлар. Чөнки озын иҗади юл үтелгән. Әле үтеләсе никадәр! Аның эшчәнлеге «Хезмәттәге батырлык өчен медале» белән бәяләнгән. Рауза Хәйретдинова башта Татарстанның атказанган артисткасы исемен алды. Аннан соң Татарстанның халык артисткасы дигән югары исемгә лаек булды. Димәк, инде аны халык үзенеке итеп таный. Рауза үзе дә иҗатының иң бөек максатын халыкка армый-талмый хезмәт итүдә күрә. Икенче яктан, образларны тасвирлау өчен, ул барлык төсмерләрне халыктан җыя, гади кешеләрнең күңел диңгезеннән чумырып ала.

Соңгы тапкыр Раузаны «Ике килен-килендәш»тә сыер савучы Камилә ролендә рәхәтләнеп карадык. Бөтен зал аның уеныннан канәгать иде. Бер генә ясалмалык та юк. Һәммә хәрәкәте чын, тормышчан.

— Үзем уйнаган рольләрдә башкаларны күрсәм, кай яклары да килешеп бетмәсә, күңелем әрни башлый,— ди Рауза,— сәхнәгә йөгереп менеп «менә шулайрак ул» дип күрсәтеп бирәсе килә. Яшьрәк чакта өлкән артистлар да миңа шулай караганнардыр. Алар мине күп нәрсәгә өйрәттеләр.

Рауза Хәйретдинова иҗатындагы уңышлары өчен иң әүвәл укыткан укытучыларына, дөрес юнәлеш биргән өлкән буын артистларга, акыллы режиссерларга бурычлы. Рауза аларны зур ихтирам белән искә төшерә. Соңгы вакытта ул үзе кайчандыр Гөлчирә ролен уйнаган «Ташкыннар»да Мөршидәне әзерләде. Бер-берсенә бөтенләй капма-каршы образлар. Бөек Октябрьның 60 еллык юбилее сезонын театр коллективы нәкъ менә «Ташкыннар» спектакле белән башлап җибәрде.

«Чорыбызның иң олы җанлы, булдыклы, бөек идеаллар белән рухланып яшәүче һәм эшләүче тирән фикерле заманыбыз хатын-кыз образы әле уйналмаган, әле мин аны уйнармын»,— дигән сүзләрен ишеткәч, мин Рауза Хәйретдиновага киләчәктә иҗат планнарыгыз нинди! дигән традицион соңгы сорауны бирүне кирәк дип тә тапмадым.

Аңлашыла бит.

Мирхәт ХӨСНИМӘРДӘНОВ.

КОТЛЫ БУЛ

Хәзерге заман туйларының иң югары, иң мөһим ноктасы — язылышу. Бернинди башка йоланы үтәү дә егет белән кызның өйләнешүен закон каршында расламый, бары тик язылышканнан соң гына закон яңа гаиләнең төзелүен таный. Язылышу бигрәк тә хатын-кыз һәм балалар өчен кирәк, чөнки закон тәртибендә рәсмиләштерелгән гаиләдә генә алар тулы хокуклы була алалар.

Язылышуны тантаналы итеп үткәрү турында РСФСР һәм Татарстан Министрлар Советларның махсус карарлары бар. Ул карарларда җирле советларга зур бурычлар йөкләнә. Совет органнары язылышуны үткәрү өчен тиешле биналар, җиһазлар булдыру өчен җаваплы, алар бу мөһим эшне тиешле югарылыкта башкарырлык абруйлы, сәләтле һәм әзерлекле кадрлар булдыруны да кайгыртырга тиешләр.

Шушы карарны үтәү йөзеннән, соңгы елларда шәһәрләрдә, эшче поселокларында бик матур итеп махсус загс биналары салына башлады. Белгечләрнең исәпләп чыгаруына караганда, тантаналы йолаларны үтәү өчен йөз мең кешелек шәһәргә бер зал җитә. Халкы аннан кимрәк булган поселокларда, авылларда, язылышу өчен клублардан, культура сарайларыннан файдаланырга мөмкин.

Хәзер бик күп авылларда гаҗәп матур, иркен культура сарайлары төзелде. Туйлар, юбилейлар өчен бинаның иркен бүлмәсен сайлау яхшы. Чөнки ни дисәң дә, кысан бүлмәдә вакыйганың зурлыгы ул кадәр үк сизелми. Аннан тыш кечкенә бер яки ике бүлмә булса, тагын да яхшырак. Алар кияү белән кәләшкә тантана алдыннан кереп, төзәтенеп чыгу өчен кирәк.

Язылышу — яңа йола, ул элек булмаган, хәзерге вакытта исә ул барлык совет кешеләре өчен дә уртак йола булып тора. Бу йоланы матур итеп үтәү турында төрле республикалар художниклары, культура-агарту әһелләре бик нык уйланалар. Өйләнешүне рәсмиләштергәндә барлык милләтләр өчен дә уртак моментлар шактый, ләкин шул ук вакытта милли традицияләрне, гадәт-йолаларны да онытырга ярамый. Мәсәлән, залларны бизәгәндә татар халкының нәкыш үрнәкләрен бик уңышлы файдаланып була.

Залның түренә өстәл куела, ул, әлбәттә, әйбәт, матур, зур булырга тиеш. Өстәл өстендә документлар салу өчен махсус папка, ручка, балдакларны салырга матур тәлинкә яки савыт була. Идәнгә ишектән алып түргәчә келәм җәелә. Бүлмәне сабагыннан әле генә өзеп алынган чәчәкләр бизи. Җәй көне моны булдыру кыен эш түгел, әлбәттә, ә менә кыш көне авыррак. Шуңа күрәдер инде, кайбер авыл Советларында өйләнешүчеләрне котлау өчен махсус ясалма чәчәкләр тоталар. Ә кайберәүләр урынын, җаен табып кына матур вазага чыршы, нарат ботаклары куя, икенче бер уңганнар авыл Советында, клубта гөлләр үстерергә тырыша. Уңган апалар безнең авылларда элек-электән гөлләрнең бик матурларын, кышын да чәчәк ата торганнарын үстергәннәр. Алардан үрнәк алып, авыл Советы хезмәткәрләре дә тырышлык күрсәтсәләр, яшь парларның тантанасы тагын да ямьләнер иде.

Тантанага лаек бина булдыру, аны тиешенчә җиһазлаудан тыш, авыл Советы хезмәткәрләре яшьләргә туй киемнәре тектерүдә һәм туй өчен кирәкле әйберләр әзерләшүдә ярдәм итә алалар. Ателье хезмәткәрләре белән элемтәгә керү, өйләнешүчеләргә балдаклар, бирнә өчен кирәк-яраклар сатып алуда ярдәм күрсәтү — аларның изге бурычы. Хәзерге заман кызлары, уку, хезмәт белән мәшгуль булып, бирнәне һәрвакытта да үз куллары белән әзерләп бетерә алмыйлар. Бу очракта аларга көнкүреш хезмәте күрсәтү оешмалары ярдәмгә килсен. Моны оештыруда да авыл Советы башлап йөри ала. Башка халыклар моңа зур игътибар бирәләр. Мәсәлән, украинлылар, үзләренең рушникларын — чиккән башлы сөлгеләрен бер дә онытмыйлар, аны һәр тантанада диярлек матур итеп куллану чарасын табалар. Нигә соң без үзебезнең кызыл башлы сөлгеләрне кулдан ташларга тиеш? Украинада сөлгеләрне хәтта язылышу тантанасында да кулланалар: яшь парны рушник өстенә бастыралар яки аларның кулларын бер-берсенә рушник белән бәйлиләр. Бездә сөлгегә басу гадәте юк, ләкин менә кияү егетләренең билләрендә, ат дугаларында, киленне каршы алганда кайнана кулында, кодаларны котлаганда алар бик урынлы, бик матур. Ул кызыл башлы сөлгеләрне көнкүреш оешмалары бүген дә әзерләп бирә ала.

Язылышуны уздырганда тантанага лаеклы музыка яңгырау бик мөһим. Кайбер авыл Советларында, яшьләр үзләре белән гармунчы алып киләләр, дип, шуңа ышанып яталар. Авыл гармунчысы уйнаган гади генә марш яки туш аларга бик җиткән сыман тоела. Ләкин мондый көнне киң яңгырашлы, тантаналы музыка яңгыравын тели күңел. Ә андый көйләрне уйнату өчен магнитофон яки радиола булдыру хәзерге көндә бер авылда да кыен мәсьәлә түгел.

Яшьләр, комсомол оешмалары үзләре дә бу эштә — махсус биналар булдыруда, аларны матур итеп җиһазлауда, өйләнешүчеләргә кирәкле әйберләрен әзерләшүдә — зур ярдәм күрсәтә алалар. Монда, кем дә булса килер дә, безнең өчен барысын да эшләп куяр, дип ышанып яту ярамый.

Күп кенә авыл Советлары туйга һәм язылышу тантанасына чакыру өчен махсус открыткалар тоталар. Бу нәрсә яшьләргә зур ярдәм күрсәтә — аларны чакыру кәгазьләре булдыру турында кайгыртып йөрү мәшәкатеннән коткара. Күптән түгел Казанда туйга чакыру өчен махсус открыткалар да басылып чыккан иде. Дөрес, алар бөтен кешегә дә җитеп бетмәс, шуңа күрә авыл Советлары чәчәкле-бизәкле матур открыткалар булдыру турында кайгыртып дөрес эшлиләр. Ул открыткаларга туйның, язылышуның көне-сәгате язылып, яшьләрнең ата-аналарына, дусларына, туганнарына тапшырыла.

Кәләшләрнең күбесе хәзер туйга ак күлмәк тектерә. Электән татарда туйга ак күлмәк кию булмаган — бу безгә башка халыклардан кергән гадәт. Әлбәттә, ак күлмәк кәләшне бизи, көннең тантанасын әллә каян күрсәтеп тора. Ләкин алсу, күксел, зәңгәрсу күлмәкләр дә кәләшләргә бик килешә бит! Монда бертөрлелеккә омтылуның һич кирәге юк. Төрле төстәге күлмәкләр тексеннәр кәләшләр, үзләренә килешкәнне кисеннәр. Тик туй күлмәгенең җиңле, ябык якалы, итәге озын булуы яхшы. Кәләшләрне тыйнаклык бизи.

Ак бөркәнчек — хәзерге кәләшләрнең бизәге. Бөркәнчекне татар кәләшләре борын-борыннан кигәннәр, тик аяар ак булмаган. Хәзерге кәләшләргә дә чигүле, челтәрле бөркәнчекләр бик килешә. Әгәр аның янына калфагы да булса, кәләшне бик тә бизәр иде. Кызганычка каршы, калфаклар кибеттә сатылмый, аларны чигә белүчеләр дә сирәк. Алай да бөтенләй үк өметсезлеккә бирелмик әле. Хәзерге көндә бездә халык һөнәрчелекләренең күп төрләре яңадан тергезелә, яши башлый, бәлки әле калфакларның да кәләшләр маңгае өстендә балкыганын күрер көннәр булыр.

Кияүләр күп очракта кара костюм, ак күлмәк кияләр. Ак күлмәк, әлбәттә, тантананы күрсәтеп тора, ләкин костюмның кап-кара булуы ул кадәр үк мәҗбүри түгел.

Тантанага кияү белән кәләш кенә түгел, рәсми актны башкарачак загс яки Совет хезмәткәре, яшьләрне котлаячак депутат та әзерләнсә, яхшы булыр иде. Аларга да киемнең вакыйгага лаегын, тантаналысын кию тиеш. Әгәр бу кешеләрнең орден-медальләре, бүләк значоклары булса, аларны да тагарга кирәк. Хәзерге вакытта мондый зур эшне башкаручылар өчен махсус значоклар булдыру хакында да сүз бара.

Авылларда да, шәһәрләрдә дә язылышырга машина белән баралар. Әлбәттә, кияү белән кәләш кебек кадер ияләренә андый зур тантанага җитәкләшеп тәпи-тәпи бару килешеп бетми. Тасмалар, өреп кабартылган шарлар аллы-гөлле куыклар белән бизәлгән,

Рәүфә **УРАЗМАНОВА**, Мәдинә **МАЛИКОВА**

...СЫН ТУЕГЫЗ!

алдына зур курчаклар куелган җиңел машиналар баштарак безнең күңелләргә бик хуш килгән иде...

Шулай да дугаларына сөлгеләр уралган, кыңгыраулар таккан пар атлар сагындырып искә төшә. Алар бик күптәннән булган, ләкин беркемнең дә күңеленә тимәгән, һәрвакыт үзенең романтикасын саклаган бит. Хәзер инде шәһәр җирендә дә яшь парны атларга утыртып урамнардан уздыруны кайгыртучылар бар. Нигә тузан туздырып, төтен таратып, машина куарга! Загс юлында алай ук ашыкмасаң да була. Шуңа күрә яшь парларны атларда йөртү турында кайгырткан кешеләр дөрес эшлиләр.

Кайбер авыл Советларында берничә парның язылышу тантанасын берьюлы үткәрергә тырышалар. Болай эшләү яхшы түгел. Гаилә кору — ул кеше гомерендә була торган иң зур вакыйга, андый чакта һәр пар үзе өчен аерым тантана үткәрүгә лаек.

Авыл Советы хезмәткәрләренә ярдәм йөзеннән, без берничә киңәш бирергә кирәк дип саныйбыз.

Язылышырга килгән яшьләрне иң элек кияү бүлмәсенә чакыралар. Урамда җил, яңгыр булуы ихтимал, язылышу бүлмәсенә матур итеп, бизәнеп керәсе килә. Шуңа күрә кәләш — үзенең дус кызы белән, кияү — кияү егете белән аерым бүлмәләрдә төзәтенеп чыга алсалар, бик яхшы. Бу вакытта өйләнешүне рәсмиләштерүче авыл Советы хезмәткәре — депутат һәм аның ярдәмчесе кирәкле документларның барысын да әзерләп куйган булалар инде.

Депутатның ярдәмчесе яшьләрне тантана залына чакыра. Анда иң алдан кияү белән кәләш, алар артыннан ике шаһит — кияү егете белән кәләшнең иң якын дус кызы, алардан соң өйләнешүчеләрнең ата-аналары, иң соңыннан туганнар, дуслар керә. Тантаналы көй яңгырый, депутат яшьләрне аягүрә басып каршы ала. Яшьләр өстәл каршына барып туктагач һәм музыка тынгач, депутатның ярдәмчесе болай дип игълан итә:

— Бүген биредә Рәмзия Исмәгыйлова белән Таһир Зиннуров никахлашалар. Аларның никахын рәсмиләштерү тантанасын авыл Советы депутаты Каюм Абдуллин башкара.

Депутат, тантананы башлап, кыска гына сүз әйтә. Монда бүген ике яшь кешенең яңа тормыш башлавын, гомернең бик җаваплы чорына аяк басуын, аларның ил каршында, халык каршында, киләчәк буын каршында зур җаваплылыкны үз җилкәләренә алуын кисәтеп үтү кирәк.

Шуннан соң ул кияү белән кәләштән аерым-аерым өйләнешергә ризалыкларын сорый:

— Рәмзия, сез Таһир Зиннуров белән гомер юлыгызны бергә узарга, аңа һәрчак тугрылыклы булырга әзерме?

— Әйе, әзермен.

— Таһир, сез Рәмзия белән гомер юлыгызны ахырынача бергә узарга, аңа һәрчак тугрылыклы булырга әзерме?

— Әйе, мин әзер.

Украинада һәм башка кайбер якларда шуннан соң яшьләрне ант иттерәләр. Алар депутат каршында, аның артыннан кабатлап, мондый сүзләрне әйтәләр:

— Без үз ихтыярыбыз белән уртак тормыш корабыз, Ватаныбызның иминлеге хакына, халыкның үлемсезлеге хакына һәм үз бәхетебез хакына, нәселебезне дәвам итәргә яңа гаиләгә нигез салабыз.

Депутат яшьләрне өстәл янына чакыра.

— Яңа гаилә төзүегезне раслап, кул куюыгызны үтенәм.

Яшьләр кул куйгач, ике шаһитка кул куярга тәкъдим ителә. Моннан соң яшьләргә никах балдакларын кигезергә мөмкин.

Депутат балдакларны ала да:

— Гаилә төзүегезнең билгесе итеп, бер-берегезгә балдак кигезегез, — ди.

Ул кәләш балдагын кияүгә, кияүнең балдагын кәләшкә бирә. Яшьләр балдакларны бер-берсенә кигезәләр. Балдак кигезгәндә тантаналы музыка яңгырый.

Шуннан соң депутат:

— РСФСРның «Никах һәм гаилә кору турында»гы законы нигезендә, шаһитлар, ата-аналар, туганнар, дуслар каршында һәм үзегезнең теләгегез буенча, мин сезне шушы минуттан ир белән хатын дип игълан итәм,— ди.

Тагын тантаналы музыка яңгырый. Депутат, өстәлдән никахлашу турындагы таныклыкны алып, яшьләргә бирә:

— Кадерле дуслар! Үзегезнең биргән антыгызның билгесе итеп һәм шушы бәхетле минутларның истәлеге итеп, хөкүмәтебез тарафыннан бирелә торган шушы олы документны кабул итеп алыгыз!

Шуны кисәтеп үтәргә кирәк: өйләнешүчеләрне ризалыгын сорау, алардан загс кенәгәсенә кул куйдыру, аларга таныклык бирү — закон тәртибендә мәҗбүри рәвештә эшләнергә тиешле эшләр.

Никахлашу турындагы таныклыкны тапшыргач, иң беренче булып депутат үзе котлау сүзе әйтә. Монда инде нык әзерлек, күңел җылысы кирәк. Илебезнең бөеклеген, халкыбыз алдында торган изге бурычларны, яңа тормыш коручыларның җаваплылыгын әйтеп китү урынлы. Кияүгә үз ярына карата кайгыртучан булырга, аңа ярдәм итәргә кирәклеген искәртү, ә кәләшкә игътибарлы һәм ягымлы хатын булырга, таза, сәламәт балалар табарга һәм аларны икәүләшеп тигез тормышта чын гражданнар итеп үстерергә кирәклеген әйтү бик мөһим. Уртак бәхет, уртак куанычлар белән бергә, тормышның гел тоташ бәйрәмнәрдән генә тормаганын искә төшерү һәм яшьләргә барлык авырлыкларны бергә күтәрергә кирәклеген әйтү дә зыян итмәс.

Депутат яшьләрнең ата-аналары турында да берничә сүз әйтеп китсә, күңелле була. Әгәр әби-бабалар булса, алар да игътибардан читтә калмасын иде. Олы буынның сугышчан батырлыклар яки фидакарь хезмәт өчен алынган бүләкләре булса, аларны әйтеп китү бик урынлы.

Депутат сүзен тәмамлауга, тантаналы музыка яңгырый.

Шуннан соң яшьләрне башкалар котлый. Бигрәк тә яшьләр эшли торган коллективларның вәкилләре сүз әйтергә омтылалар. Сүзләр кыска, мәгънәле, күңелләрне тетрәтерлек хисле булырга тиеш.

Шуны да истә тотарга кирәк: озын-озын итеп теләкләр теләргә, тостлар әйтергә үз урыны — туй мәҗлесе бар. Бүләкләрне дә шунда тапшырырга була.

Кайбер авылларда тантаналы язылышу вакытында яшьләрне үбештерәләр. Бу гадәт безнең халыкның күңеленә бик үк ятышып бетми, чөнки бездә кеше алдында үбешү һәм аны карап тору элек-электән тыйнаксызлык саналган. Андый чакта бигрәк тә яшьләрнең ата-аналары кыенсына.

Язылышу вакытында кияү белән кәләшкә ипи-тоз бирүне дә хуплап булмый. Ипи—татар халкында борын-борыннан изге нәрсә санала, туй өчен махсус пешерелгән күмәчләрне кода-кодагыйлар зур күчтәнәч итеп күтәреп баралар. Ләкин загска аны күтәреп бару урынлы микән?

Безнең халыкта бу йола башкачарак формада яши: кияү йортына төшкәндә, киленгә ипи белән май яки, аннан да яхшырагы, бал-май белән каршы алса, алар саф татарча иттереп, чигүле ашъяулыкка куелган булса, бу халык күңеленә ятышлырак күренә. Ашъяулыкка чәкчәк куярга, киленне шуның белән авызландырырга да ярый торгандыр — чәкчәктә ипие дә, бал-мае да бар бит. Һәрхәлдә, бу йоланы үткәрүнең урыны загс түгел.

Загс бинасында тантаналы язылышу үткәннән соң фоторәсемгә төшәләр.

Загстан чыкканнан соң Билгесез солдат каберенә яки Гражданнар сугышы корбаннарына һәм Ватан сугышында һәлак булган якташлар истәлегенә куелган һәйкәл янына барып чәчәк куюн гадәте дә бар. Бу — яшьләрнең үткән буынга рәхмәте, аларга ихтирамы һәм алар каршында бурычын аңларга теләү билгесе. Яшьләр гариза бирергә килгәндә үк моны аңлату бик урынлы булыр иде.

«ҖАН ҖӘРӘХӘТЕ»

Шушы баш астында, журналыбызның узган елгы 9 нчы санында медицина фәннәре докторы Баһрам Садыйковның мәкаләсе басылып чыккан иде. Анда пенсионер Садыйк аганың Даимә исемле олы яшьтәге врач белән йөрүе һәм шуның аркасында Садыйкның хатыны Җәүһәриянең сәламәтлеге какшавы турында сүз бара. Безнең күп кенә укучыларыбыз бу мәкаләгә карата үзләренең фикерләрен язып җибәрделәр. Түбәндә без аларның берничәсен урнаштырабыз.

«Минемчә, мәкаләнең авторы Баһрам Садыйков бу мәсьәләгә бик дөрес карамый. Аның мәкаләсендә Даимәнең гаебен җиңелчә генә аңлатырга тырышу сизелә. Семьяны бәхетсезлеккә дучар итүче бит ул Даимә! Ә Садыйк картка ике хатынның берсен сайларга киңәш итүне ничек аңларга? 60 яшьлек картлар шулай сайлана башласалар, безнең тормыш бик ямьсезләнеп китмәсме? Ә Җәүһәриягә бу фаҗигане җиңел кичерергә кушкан тагын. Утыз ел бергә гомер иткән иренең хыянәтен күреп торган авыру хатынга ничек җиңел булсын? Мондый очракта, намуслы, гомер иптәшенә тугрылыклы булырга, үз-үзеңне тыярга кирәк, дию тиеш иде. 1965 нче елда «Азат хатын»да «Үз-үзеңне тота бел» дигән мәкалә басылган иде. Садыйкка менә шул мәкаләне укып сабак алырга кирәк.

Я. Б.
Бакалы».

* * *

«Нигә дип ул Садыйк Даимә янына бара икән? Әгәр өйдә тормыш иптәшең сине ярата икән, ягымлы икән, аны ничек ташлап китәсең? Ә бәлки Садыйкның тормышы икенче төрледер? Мин шундый хәлне беләм: бер кеше, балаларын үстереп бетергәч, бөтен йорт-җирен, малтуарын хатынына калдырып, 55 яшьлек тол хатын янына барып керде. Аңа җиңел булды микән гомер буе бар иткән милкен ташлап китүе? Димәк, хатыннан тәмам гайрәте чиккән булган аның. Кайчак шулай да була: ир ни әйтсә дә, хатынга ошамый, ни эшләсә дә — ярамый. Бергәләп киногa бару юк, рәхәтләнеп ял итү юк, шул булдымы тормыш! Әлбәттә, мин Садыйкны акламыйм, аны болай да бөтен кеше гаеплидер. Ләкин хатыннарга да мәхәббәтне, яхшы мөнәсәбәтләрне саклый белү кирәк. Чөнки бер аралар бозылгач, килешсәң дә, җан җәрәхәтенең эзе кала, һаман сызлап, сиздереп тора.

А. Я.
Буа».

* * *

«Җәүһәрия белән Садыйкның тормышы нәкъ безнеке төсле икән. Без бик яшьли яратышып өйләнештек. Иптәшем бик көнче булып чыкты, мин, ул сүз әйтмәсен дип, эшкә дә йөгереп барып, йөгереп кайта торган идем. Болай куркып яшәү мине гел өйдә торырга күнектерде, мин күңел ачу, кино карау дигән нәрсәне белмәдем. Ә иремнең эше кешеләр арасында, күренекле урында иде. Кызым тугач, бер ел өйдә утырдым, аңа яшь тулгач, эшкә чыктым. Тагын эшкә йөгереп барулар, йөгереп кайтулар башланды, нигә шул кадәр куркак булганмын, хәзер аңламыйм. Ирем бала тәрбияләү, кибеткә бару, өйдә ярдәм итү ишене белмәде, чиста, үтүкләнгән киемнәрен киеп эшенә китте, ә минем күзгегә карарга да вакыт булмады. Тормыш ага торды, ирем үзгәрә барды, ул хәтта үтүкләнгән якасына да бәйләнә башлады, ә мин һаман аңа ярарга тырыштым. Шулай ун ел яшәдек, ирем ике ел рәттән икешәр тапкыр больницада ятып чыкты, мин аны, Җәүһәрия ирен караган кебек, карадым. Шуннан соң мин иремнең инде өч ел башка берәү белән йөргәнен белдем. Алар бәйрәмнәрдә бергә күңел ачканнар (ул өйдән, эшкә барам, дип чыгып китә иде), парлап киноларга йөргәннәр. Бу хәлне мин бик авыр кичердем. Дөрес, балам хакына, дип аерылырга батырчылык итмәдем, әмма үзем чиргә сабыштым... Без икенче җиргә күчеп киттек, ләкин озак та үтмәде, яңа урында ирем үзенә яңа «яр» тапты. Хәзер без өйдә квартирантлар кебек яшибез, ә күңел, йөрәк — ташка әйләнгән. Яшь дуслар, үзегезнең кадерегезне минем кебек югалтмагыз!

В. ГӘРӘЕВА,
Октябрьск шәһәре».

* * *

«Баһрам иптәш Садыйковның кайбер җөмләләре ике карт кешенең бозыклыгын, азгынлыгын яклауга кайтып калган. Андыйлар турында «рухи якынлык, күчле хис, җан сөйгән» дип сөйләргә оят. Аларга кеше алдында һәм балалары алдында горурлыкларын саклап яшәргә вакыт җиткән. Үзенең азгын күңеленә хуҗа була алмыйча, кеше семьясына тыкшынып, аны таркатучы Даимә ишеләр белән бөтен җәмәгатьчелек, җирле советлар, партоешма көрәшергә тиеш. Семья тормышын гадәттә, эчкечеләр һәм азгыннар тарката. Нәкъ менә шул ике нәрсә кешегә күпме газаплар, бәхетсезлекләр китерә. Садыйк картка шуны әйтәсе килә: гомер буе хатын өстен-

«ГҮЗӘЛГӘ АК

«Журналның узган елгы 7 нче санында басылган «Гүзәлгә ак күлмәк» исемле мәкаләне укыгач, кулыма каләм алмый булдыра алмадым. Гүзәлнең әнисе авырый, ә кыз мәктәпне тәмамлый, аның чыгарылыш кичәсенә ак күлмәк, ак туфли киясе килә. Күрше карчыгы Фатыйма Гүзәлне, үзеңне генә уйлыйсың, дип тиргәгән. Мин Гүзәлне чын күңелдән кызгандым. Үз башымнан узган хәлләр исемә төште. Үскән чагымда киярга матур киемнәрем булмады, шуңа бик кимсенә идем. Бер заман бөтен иптәшләрем «Тарзан» киносын карарга киттеләр, ә мин бара алмадым, акчам булмады. Шунда үзәгем өзелгәннәре гомер буе онытылмый... Фатыйма монда һич хаклы түгел, Гүзәлгә ярдәм итәргә кирәк иде.

Фагыйлә Р.
Курган өлкәсе».

* * *

«Гүзәлләрнең тормышы безнекенә охшаган икән. 73 нче елда минем ирем бик нык авырды. Шул елда сигезенче класска күчкән улым Илшатны, үзем авыр булса да, ял итсен, дип, ялга җибәргән идем. Өч көннән иремнең авызына су тамызып саклый башладым, Илшатны чакырып кайтарырга туры килде. Илшат кайтты, әни, мин көндез эшлим, төнлә әтине карыйм, диде. Көндезләрен 5 нче класста укый торган улыбыз Ришат әтисен карады. Илшат шул җәйдә 400 сум акча эшләде, ә көзен мамык җыеп 100 сум алып кайтты, аңа отличник эшче дигән язу бирделәр. Шуның өстенә балалар әтиләрен дә бик нык караштылар, тәрбияләштеләр. Без бөтен семья белән үлемгә каршы көрәштек һәм җиңдек. Икенче елны, әтиләре кырыена куйган суны алып әчәрлек хәлгә килгәч, Илшат энесе Ришатны да эшкә алып китте. Уларым: «Җылы сөт эчсә, әтигә көч керер, без эшләгән акчага сыер алыйк», — диделәр һәм сыер алдык. Ә инде 10 классны бетер-

нән йөргән бер кеше бар бездә. Хатыны йөрәк белән үлеп китте, агайга сөеркәсе дә килмәде. «Мин үземне генә кайгыртып яшәргә өйрәнгән, сиңа нәнкә булалмыйм», — дигән. Хәзер үз хатынының исемен кычкырып, йорт буйлап йөри агай. Садыйк карт та шул көнгә калмас микән?

Сәлам белән, без күбәү.
Чирмешән районы».

* * *

«Утыз ел бергә гомер иткән, бөтен кайгысын, авырлыгын бергә күтәргән, эшендә орденнар белән бүләкләнгән, шундый олы йөрәкле Җәүһәрия апаны икенче берәүгә алмаштырган Садыйк мине гаҗәпкә калдырды. Ун ел буе үзенә хыянәт иткән ирен авырлык ничек тәрбияли алган ул Җәүһәрия! Олы йөрәкле, сабыр хатындыр ул. Даимә белән Садыйкның мөнәсәбәте ярату түгел, түбәнлек. Кеше күз яшьләренә корылган бәхет бәхет булалмый. Бармы икән ул Даимәнең балалары, дуслары? Алар бу хурлыклы вакыйганы ничек кичерәләр икән? Ул нинди коллективта эшләгән? Нәрсә караган профсоюз, партия оешмалары, ни өчен аны юлга бастырмаганнар? Шуны беләсе килә.

Хәнифә КЫЯМОВА,
Казан».

* * *

«Садыйк: «Мин хатынымны кызганам, шуңа күрә ташламыйм, өйгә кайтам, аңа ни кирәк тагын»,— дип хатынынnan көлә. Бер йортта эт тә, башка хайваннар да яши, ләкин алар гомер иткән тормыш иптәшен алыштыра алмыйлар. Җәүһәриягә карт көнендә якты чырай, яхшы киңәш, турылыклы тормыш иптәше кирәк. Бәһрам Садыйковның җавабына килсәк, ул: «Сөяргә хокукы бармы аның?»— дип сорый. Бу хокукка өйләнешмәгән яшь егетләр белән кызлар ия, 57 яшьлек чит хатын белән 60 яшьлек семьялы ирнең андый хокуклы чаклары үткән инде.

С. З.
Ульяновск өлкәсе».

КҮЛМӘК»

гәндә, Илшат 600 сум акча эшләде, аңа эше өчен мәктәптә комсомол җыелышында зур бәя бирделәр. Әгәр минем улларым Гүзәл кебек булсалар, без әтисез калган булыр идек. Минем улым 3 ел бер костюм киеп йөрде, шуның белән армиягә китте. Көн аралаш хаты килеп тора, һаман әтисен сорый. Мин эшләп укырга ниятләдем, чөнки тагын өч энемне кеше итәсе бар бит әле, дип яза.

Мин күп яздым, чөнки әнисе чирле чакта Гүзәлнең кыйбатлы кием соравы нигәдер күңелемә бик авыр тоелды.

Сәбилә СИРАЕВА.
Үзбәкстан».



ТАНСЫК СҮЗЛӘР

Аның белән ул беренче мәртәбә район милиция бүлегендә очрашты. Чәчләре тузгыган, хәмер чөмерүдән күзләре шешенгән, ертык күлмәкле бу яшүсмергә карап торуы оят та, кызганыч та булып тоелды. Бик яшь бит әле. Уникe-унөч яшьләр тирәсе генә булыр.

— Менә шундыйрак «егетләр»дә очрый бездә, шулар белән эшләргә туры киләчәк, Илсөя Мансуровна,— диде милициянең балалар бүлмәсе өлкән инспекторы Валентина Сергеевна.— Иң мөһиме, җәмәгатьчелек белән, яшүсмерләрнең үзләре белән тыгыз элемтәдә бул. Ә без ярдәмне кызганмабыз.

Илсөянең яңа гына кияүгә чыгып, тормыш корып җибәргән еллары иде бу. Комсомол райкомы путевкасы белән Совет районының яңа төзелгән Горки поселогындагы 20 нче йортлар идарәсенә педагог-оештыручы булып килде ул. Казан дәүләт университетының тарих бүлегендә читтән торып уку белән шундый тынгысыз хезмәтне бергә бәйләп алып бару мөмкин булмас кебек тоелган иде.

Милициянең балалар бүлмәсендә юлдан язган үсмерләр белән еш очрашырга туры килде Илсөягә. Яшь педагог аларның мондый юлга басуларының сәбәбен аңларга омтылды.

— Әнә футбол кырында сул якта ярымсакчы булып уйнаучы малайны күрәсезме? — ди Илсөя, кайчандыр булган бер вакыйганы искә төшереп.— Сары чәчле шушы малай өйдәге тәртипләр белән килешә алмый. Кача. Һәм теләсә кайда кунып, урлашып йөри башлый...

Яшь педагог аның белән очраклы рәвештә таныша. Яңа оешкан футбол командасына уенчылар кирәк була. Йорт идарәсе каршындагы мондый командаларның саны хәзер егермедән артып китә. Ә ул вакытта беренче карлыгач кына була әле ул.

Футбол уйнарга теләгән малайлар теге сары чәчлене дә үзләре белән ияртеп алып киләләр. Уен башланып китә. Шул чак мәйдан уртасына берәү атылып керә дә, теге сары чәчленең колагыннан эләктереп, читкә таба өстери. Ә теге мескен нишләргә белми...

Соңыннан шунысы ачыклана: сары малайны эзәрлекләүче кеше аның әтисе икән. Илсөя Фокеева малайның үзе белән дә, әтисе белән дә ныклап сөйләшә, өйдәге хәлләр белән таныша, малай укый торган 79 нчы мәктәптә була, укытучылар, пионер һәм комсомол активы белән аралаша.

Педагог-оештыручының ярдәмчесе булып киткән яшүсмер активистларның һәркайсы турында шулай иркенләп сөйләргә мөмкин. Хикмәт анда түгел. Илсөя тәрбиягә авыр бирелүчән үсмерләр йөрәгенә ачкыч таба белә.

Бу зур иҗади эштә аңа «Данко» исемле балалар-яшүсмерләр клубы каршында эшләп килүче дистәләрчә түгәрәкләр ярдәмгә килә. Кемнең нәрсәгә сәләтле булуына карап оештырылган бу секцияләр, түгәрәкләр балаларның буш вакытын дөрес һәм файдалы итеп үткәрүнең үтемле чарасы булып торалар. Мисал өчен, шул ук футбол командаларын гына алыйк.

Футбол яратучы яшүсмерләр яхшы хәтерлиләрдер, элеккеге елларда шәһәр беренчелеге ярышларында Дербышка поселогы малайларына каршы тору, аларны җиңелергә мәҗбүр итү мөмкин түгел иде. Ә һәркемнең финалга чыгу омтылышы зур, һәркемнең үз күкрәгендә чемпион медален күрәсе килә. Ә моның өчен, мәгълүм булганча, омтылыш кына җитми. Ихтыяр көченә тәҗрибә һәм акыллы киңәшне дә кушарга кирәк. Илсөя шушы хакыйкатьне яхшы аңлый һәм үз тирәләрендә урнашкан заводка бара. Профсоюз, комсомол комитетларында була. Хәлне аңлата.

— Илдар Ярулловичтан да әйбәтрәк кеше булмастыр,— диләр заводта. Чыннан да, электрик Илдар Габидуллин элекке елларда балаларның футбол командасына җитәкчелек иткән, алар белән уртак тел таба белгән. Әмма ниндидер сәбәпләр аркасында, ул бу изге эшне ташлаган һәм заводка эшкә урнашкан.

Илсөя булачак тренер белән озаклап сөйләшә һәм Илдар Габидуллинның бөтен күңеле балаларда икәнен аңлый.

Җәмәгать тәртибендә эшләүче тренерның беренче уңышлары бик тиз күзгә күренә башлады. Совет районының 20 нче йортлар идарәсе каршындагы футболчылар командасы иң башта район, аннан шәһәр беренчелегендә отты. Республика ярышларында да «Данко» сер бирмәде. Узган ел алар, «Күн туп» клубының Бөтенсоюз финал ярышларында катнашып, уңышны коллектив уен гына хәл иткәнен тагын бер кат күрделәр.

Сәләтләренә карап оештырылган түгәрәкләрнең һәм секцияләрнең тагын икесе турында әйтеп китү кызыклы булыр.

«Данко» балалар-яшүсмерләр клубы каршында нәниләр өчен «Буратино» дигән курчак театры эшли. Аны оештыруда Илсөягә Казан педагогия училищесында укучы кызлардан Рәдифә Бәширова белән Анфиса Захарова зур ярдәм күрсәткәннәр. Ә курчаклар тегүдә, сәхнә коруда балалар үзләре башлап йөргәннәр. Рольләрне дә үзләре башкарганнар.

Балалар клубының бер стенасына нәниләр ясаган төрле уенчыклар, сувенирлар куелган. Арада 90 нчы мәктәп укучысы Рамил Галиев эшләгән картиналар аеруча күзгә ташлана. Фанерага яндырып, көйдереп эшләгән бу сувенирларда Рамилның дөньяга карашы чагыла. Әнә аның туган як табигате турындагы картинасы. Яшь автор Татарстаныбыз табигатен бөтен матурлыгы белән ачарга омтылган. Ә бусы «Фашизм үтә алмас!» дигән рәсем-гравюра. Чили вакыйгаларына карата ясалган әлеге рәсем яшүсмернең интернациональ хисләре турында сөйли.

...Шушы елның июнь аенда Илсөя Фокеева Казан дәүләт университетын тәмамлап диплом алды. Бу көнне аның өенә бер төркем яшүсмерләр килде. Һәркайсының кулында — чәчәкләр бәйләме. Һәркайсы матур итеп котлау сүзе әйтте. Ә Илсөягә иң ошаганы теге сары чәчле малайныкы булды. Юк, әллә ни дип тә әйтмәде ул үзе, купшы сүзләре дә юк иде. «Котлыйм! Рәхмәт инде сезгә»,— диде. Бары тик шул гына. Ә нинди якын, тансык булып ишетелде ул сүзләр...

Сәмигулла ХӘЙРЕТДИНОВ.



Ашказаны асты бизе

[ОЛЫ ЯШЬТӘГЕЛӘР ӨЧЕН]

Күренекле физиолог И. М. Сеченов: «Ашказаны асты бизе турында бик күпләр белмиләр дә, ә азыкларның эшкәртелүендә шушы бизнең согы башка барлык факторларга караганда да мөһимрәк», — дип язды. Ашказаны асты бизе эшләп чыгара торган соктагы ферментлардан башка ашларның нормаль эшкәртелүе мөмкин түгел. Ниндидер сәбәпләр аркасында бу сокның күләме кимесә, азыкларның эшкәртелүе һәм үзләштерелүе бозыла, кешенең ашаганнан соң сару кайный, косасы килә башлый, аппетит начарлана, эч күбә һ. б.

Ашказаны асты бизе эшләп чыгара торган гормоннар турыдан-туры канга керәләр һәм матдәләр алмашынуында, барыннан да бигрәк углеводлар алмашынуында актив катнашалар.

Углеводлар алмашынуының төп гормональ регуляторы — инсулин. Ул бизнең барлык тукымасында түгел, ә бәлки аерым күзәнәкләр тупланган урыннарда — Лангерганс «утраучыклары»нда гына эшләнеп чыга. Инсулин аркасында глюкоза үзгәрә һәм гликогенга әйләнә, аның запасы бавырга, мускулларга җыела. Артык шикәр инсулин бүленеп чыгуны арттыра. Гормон шунда ук шикәрне гликогенга әйләндерә, ә гликоген бавырга җыела, һәм, киресенчә, әгәр организмга шикәр аз керсә, инсулин әзрәк бүленеп чыга. Шул юл белән канда шикәрнең нормаль күләмдә булуы саклана.

Кеше картая барган саен ашказаны асты бизе ничек үзгәрә соң?

Бизнең тукымаларында ул үзгәрешләр 40—45 яшьтән соң сизелә башлый. Бу чорда аның функциональ күзәнәкләре кими, аларны акрынлап тоташтыргыч тукыма һәм май күзәнәкләре баса. Бизнең сок бүлеп чыгаруы кими. Яшь кешенең бу бизе тәүлек эчендә 1200 дән 2000 миллиграммга кадәр сок ясаса, карт кешедә бу 500—600 миллиграмм гына була. Шулай да режим белән дөрес тукланганда, аш кайнату органнарының эшчәнлеге бозылмый. Инде нәфесеңне тыя алмыйча, кыздырылган, майлы ризыкларны, ысланган яки татлы ашларны күбрәк ашасаң, кикертә, сару кайный, эч күбеп китә. Карт кешенең ашказаны асты бизе мондый «йөкне» күтәрә алмый һәм бу хәл аш эшкәртелүенең бозылуына китерә.

Исерткечләр дә ашказаны асты бизе секрециясен икеләтә кимәтә. Шуңа күрә олы яшьтәгеләргә бәйрәм һәм гаилә тантанасы көннәрендә дә бер кружка сыра яки бер чәркә йөзем шәрабы белән канәгатьләнү яхшы.

Ашказаны, үт куыгы, уникеилле эчәгесендәге төрле авырулар да ашказаны асты бизенең эшчәнлеген бозарга бик мөмкин. Бу органнар физиологик яктан үзара шулкадәр тыгыз бәйләнгәннәр ки, берсенең эшчәнлеге аз гына үзгәрсә, башкаларына аның йогынтысы тими калмый. Гастрит, ашказаны һәм уникеилле эчәге язвасы, колит, холицестит белән авырганда ашказаны асты бизенең эшчәнлеге начарая. Бу авыруларны аздырырга ярамый. Вакытында врачка күре-



Сырдан, ягъни сыр кулланып, бик күп төрле тәмле ашлар әзерләп була.

СЫР ҺӘМ АЛМА САЛАТЫ

100 г сыр, 1 алма, 2 бал кашыгы горчица, майонез алына.

Сырны һәм алманы вак кына итеп турарга. Горчица белән майонезны бергә кушып болгатырга, тәменчә шикәр һәм тоз өстәргә. Шуны туралган сыр һәм алма өстенә салып, өстен яшел салат яфрагы белән бизәргә.

СЫР БЕЛӘН ТУТЫРЫЛГАН ЙОМЫРКА

200 г сыр («голландский» тибындагы), 4—6 йомырка, аш кашыгы белән кашык ярым май, ике кашык каймак, әч кашык майонез алына.

Каты пешкән йомыркаларны кабыгыннан арчып, буйга урталай ярырга, сарысын алырга һәм аларны кыргычта уылган сыр һәм акмай белән кушып изәргә. Шушы катнашманы йомыркаларга тутырырга. Уылган сырның калганын каймак белән болгатып салат савытына салырга, өстенә сыр тутырылган йомыркаларны тезәргә, өстенә майонез сибеп, яшел суган кыяклары яки петрушка яфраклары белән бизәргә.

БӘРӘҢГЕЛЕ СЫР ШАРЛАРЫ

40 г ак май, 200 г пешкән бәрәңге, 50 г он, 1 йомырка, 65 г уылган сыр, тоз, мөшкәт чикләвеге яки борыч алына.

Эретелгән майга бәрәңгене, онны, сырны һәм тәменчә тоз салып, бер йомырканы сытып, барысын бергә бик әйбәтләп болгатырга. Шушы массадан шарлар ясап, сохари онында әвәләргә һәм кайнап торган майга салып кыздырырга кирәк.

СЫР КУШЫЛГАН ТОКМАЧ АШЫ

Ике кашык ярым сөт, 3 йомырка, 3 стакан кыргычта уылган сыр, 20 г акмай, тоз алына.

Коштабакка сөт салып, шуңа уылган сырны, йомырка һәм тәменчә тоз салып, барысын бергә бик әйбәтләп болгатырга. Шушы массаны майлы табага салып кызу мичтә белен итеп пешерергә. Аннары ул беленнәрне духовкада бераз киптереп алырга, эрерәк итеп токмач кисәргә. Шушы токмачны ит шулпасына салырга.

БРЫНЗАЛЫ БӘРӘҢГЕ КОТЛЕТЫ

Ике кешелек итеп әзерләү өчен 250 г бәрәңге, 100 г брынза, 2 йомырка, 20 г дөге, он, үсемлек мае, борыч алына.

Бәрәңгене кабыклы көе пешерергә, кабыгын әрчеп, суытырга, аннан кыргычта уарга. Дөгене бүрттереп алырга һәм бәрәңге белән болгатырга. Шуңа уылган брынза, йомырка салып, җайлап кына болгатырга. Шуңа вак кына итеп туралган яшел петрушка салырга мөмкин. Теләсәгез кара борыч та өстәргә мөмкин. Әзерләнгән массадан котлетлар ясагыз, аларны ак онда әвәләгез, туглаган йомыркага да манып алырга мөмкин. Аннан соң үсемлек маенда кыздырырга кирәк.

СЫР КУШЫП ӘЗЕРЛӘНГӘН КӘБЕСТӘ ТӘБӘСЕ

2 кг кәбестә, 2 кашык ак май, 3 кашык туралган суган, 3 кашык бодай оны, ярты бал кашыгы мөшкәт чикләвеге, чирек бал кашыгы яңа төелгән хуш исле борыч, 2 стакан сөт, 1 данә лавр яфрагы, 1 стакан уылган сыр, 3 аш кашыгы сохари оны алына.

Кәбестәне тапап, кайнаган суга салып, 10 минут пешерергә, иләк өстенә салып суын саркытырга. Акмайны табага салып эретергә, туралган суганны шушы майга салып 5 минут кыздырырга. Шуңа он, мөшкәт чикләвеге, тоз һәм борыч өстәп әйбәтләп болгатырга. Шуңа сөтне аз-азлап салып, әзлексез болгатып торырга. Кайнап чыккач, лавр яфрагы салырга, акрын ут өстендә 20 минут пешерергә. Шуннан соң яфракны алып ташларга һәм табадагы массага уылган сырның $3/4$ стаканын өстәргә. Шуны кәбестә белән кушып болгатырга, тәменчә тозларга, тирән табага салырга. Калган сырны, сохари оны белән болгатып, табадагы масса өстенә сибәргә. Табаны 210 градуска кадәр кыздырылган духовкага куеп 15 минут пешерергә яки кәбестәнең өсте кызарганчы тотарга.

СЫР ӨСТӘЛГӘН МАКАРОН ЗАПЕКАНКАСЫ

250 г макарон, 50 г ак май, 3 йомырка, 2 аш кашыгы каймак, ярты стакан уылган «голландский» сыр, 15 г төелгән сохари, тәменчә тоз, 1 аш кашыгы сөт.

Макаронны тозлы шулпада пешерергә, тишекле тустыганга салып, суын саркытырга, аннан макаронны икенче савытка бушатырга, ак май (20 г) өстәп болгатырга. Аерым савытта 2 йомырка сарысын тоз салып тугларга, каймак кушып болгатырга, уылган сырны өстәргә һәм шушы макарон белән болгатырга. Аннары ике йомырканың агын туглап салырга һәм җайлап кына болгатырга кирәк.

Майланган табага сохари оны сибәргә, шуңа әзерләп

нергә, врач кушканча дәваланырга кирәк. Үт куыгы яки үт юлларында таш булган очракта врач киңәшләренә аеруча игътибар таләп ителә, чөнки панкреатит, ягъни ашказаны асты бизе ялкынсынуы нәкъ әнә шундый авыруларда еш була.

Кеше картая барган саен аның ашказаны асты бизенең канда шикәр күләмен чамалауга сизгерлеге кими. Чөнки биз җитәрлек кадәр инсулин бүлеп чыгара алмый башлый. Глюкоза организм тарафыннан тулысынча үзләштерелми һәм бәвел белән бергә организмнан бүленеп чыга башлый: шикәр чире килеп чыгуга сәбәпче шартлар туа.

Олы яшьтәге кешеләрдә һәм картларда еш кына шикәр чире беленмәскә дә мөмкин. Шуңа күрә үзеңә игътибарлы булырга, хәлсезлек йөдәтсә, тиз арысаң, бәвел бүленеп чыгуы артса, авызың кибеп йөдәтсә, врачка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Ашказаны асты бизен саклагыз! Кайчагында туклану диетасын саклау, шикәрне, кондитер һәм камырлы ризыклар ашауны чикләү дә хәлне нормальләштерә.

Ашказаны асты бизенең функциясе бозылмавын саклауда туклану режимы мөһим роль уйный. Аксымнарга бай ризыклар, шулай ук пешкән ит, балык ашарга кирәк. Туклану рационында кефир, әчегән сөт, эремчек булырга тиеш. Сөт продуктлары җиңел үзләштереләләр, ашказаны асты бизенә уңай йогынты ясыйлар.

Көнлек туклануда бәрәңге белән бергә санап, 600 граммнан ким булмаган күләмдә яшелчәләр булырга тиеш. Шуларның бер өлешен чи килеш ашарга кирәк. Чи яшелчәләрдә С витамины күп була. Организмда матдәләр алмашынуында аның роле аеруча зур. Җиләк-җимеш (алма, кара карлыган, гөлҗимеш, кара җимеш) аш эшкәртү органнарының эшчәнлеген җайга сала.

Үсемлек майларыннан — көнбагыш белән кукуруз мае аеруча файдалы.

Олы яшьтәге кешеләргә җиңелчә үткудыргыч эчемлекләр — гөлҗимеш төнәтмәсе, үткудыргыч чәй эчәргә тәкъдим ителә. Болар үт бүленеп чыгуны активлаштыралар, үт юлларының эшчәнлеген арттыралар. Төнәтмәләрне ашаудан ярты сәгать алда, көнгә өч тапкыр ярытышар стакан (җылы көе) эчәргә кирәк.

Тиз юанаючан кешеләргә ипине көнгә 150 грамм гына ашарга тәкъдим ителә.

Консервланган, кыздырылган ризыкларны, горчица, борыч кебек тәмләткечләрне күп кулланырга ярамый.

Һәр көнне бер үк вакытларда көнгә 4—5 тапкыр ашарга кирәк. Организм билгеле бер режимга күнә һәм аш вакыты җитү белән ашкайнату бизләре сок бүлеп чыгара башлыйлар, аппетит ачыла, ризык яхшырак үзләштерелә.

Кырыктан узган кешеләргә туйганчы ук ашарга ярамый. Артыгын ашау юанаюга китерә, йөрәкнең һәм аш эшкәртү органнарының хәлен кыенлаштыра.

Ашау-эчүне төрләндереп тору әйбәт. Бүгенге ризыклар кичәгедән мөмкин кадәр үзгә булсын. Ризык ничек кенә тәмле булса да, организм аны көн саен кабул итәргә теләми.

Атнага бер тапкыр бушану көне ясау яхшы: бу көнне 1 литр кефир һәм 400 грамм алма яки 1 литр җиләк-җимеш согы һәм 400 грамм эремчек кенә ашарга киңәш ителә.

Тагын бер киңәш. Иртәнге гимнастика комплексына корсакка массаж ясауны кертегез. Тезләрне чәнчеп яткан килеш сәгать стрелкасы йөреше уңаена түгәрәк хәрәкәтләр ясап 5—7 минут корсакны сыйпап торырга кирәк.

куелган макаронны салырга, өстенә 1 йомырканы сөт белән туглап сөртергә, төелгән сохари сибәргә һәм духовкага куеп өсте кызарганчы пешерергә. Табынга чыгарыр алдыннан өстенә бер кашык эретелгән акмай сибәргә кирәк.

СЫР КОЙМАГЫ

2 стакан он, стакан ярым сөт, 2 йомырка, 250 г сыр («советский» яки «голландский»), 50 г сары май, тәменчә тоз.

Йомырканың сарыларын тоз салып тугларга, сөт һәм он өстәп, камыр изәргә. Шуңа йомырканың агын туглап салып болгатырга. Камыр каймак куелыгында булырга тиеш. Сырны юка итеп дүртпочмаклы кисәкләргә турарга. Кызган майлы табага берәр кашык камыр салып, һәркайсының өстенә берәр кисәк сыр куеп чыгыгыз, коймакның асты пешкәч, әйләндереп икенче ягын пешерегез. Өстәвенә сары май сибеп ашарга.

СЫР ЮКАСЫ

200 г төче камыр, ярты стакан уылган сыр («голландский»), 50 г акмай алына.

Төче камырдан, таба зурлыгында итеп, бик юка түгәрәкләр җәегез. Аларны кызу духовкага куеп бераз катырып алыгыз. Аннары юканы табага салыгыз, өстенә уылган сыр сибегез, өстенә икенче юканы каплагыз да эретелгән акмай сибеп духовкада пешереп алыгыз.



Утюгтагы крахмал яки тутык табын бетерү өчен юеш чүпрәк өстенә әре тоз салыгыз һәм кызу утюгны шуңа басып ышкыгыз, аннан коры чүпрәккә ышкыгыз.

* * *

Яңа теш щеткасын берничә сәгать тозлы суга тыгып торырга, аннан сабынлап җылы су белән юарга кирәк.

* * *

Кыздырганда балык табага ябышмасын өчен, аны кыздырасы майга бер чеметем тоз салыгыз. Ит кыздырасы булса, майга берничә тәгәрмәч кишер салыгыз.

* * *

Тавык шулпасына суган һәм кишердән кала тәмләткечләр салмагыз — шулпаның тәме югала.

* * *

Кара йон тукымадан тегелгән күлмәкне югач, соңгы тапкыр аш серкәсе кушылган (бер чиләк суга 3—4 аш кашыгы) суда чайкагыз.

* * *

Йозакта авыр борыла торган ачкычны балавыз яки сабын белән ышкыгыз.

* * *

Мех һәм йон баш киемнәрен өйдә, җылы бинада киеп йөрмәгез — баш тирле, чәчләр дымланучан, тиз керләнүчән һәм коелучан була. Ә урамга чыккач салкын тидерүегез турында әйтеп торасы да юк.

* * *

Кышкы салкыннарда перчәткә киюгә караганда, иркенрәк бияләй кисәң, җылырак була. Алай да куллагыгыз туңса, өйгә кергәч аларны башта салкын су белән, аннан бүлмә температурасындагы һәм җылымса су белән юыгыз һәм корылатып сөртегез. Өйдә кулыгызга майлы крем сөртегез.

* * *

Салкын көнне кибеткә азык-төлек алырга сетка белән бармагыз — аның нечкә бавы кулны кисә, бармакларга кан йөреше тоткарлый, шулай булгач, бармакларыңны өшетергә дә күп кирәкми. Киң баулы сумка яки кәрзин әйбәтрәк.

ЧҮПРӘК САКЛАУ ӨЧЕН УРЫН

Тузан сөртә торган чүпрәкне саклау өчен курчак кыяфәтле янчык ясарга мөмкин һәм ул бик уңайлы да була. Ул болай эшләнә. Төбенә кую өчен диаметры 15 см зурлыгында фанердан түгәрәк киселә, чүпрәк белән тышлана. Шуңа югарыга таба тарәеп менгән янчык тегелә, курчакның буеннан-буена ярык ясала. Янчыкның югары башына иске курчак башы беркетелә, элгеч ясап, курчакны кухняга элеп куясың. Калдырылган ярык аркылы чүпрәкләрне шушы курчак эченә салып куясың.

ТАБИГАТЬ СЕРЛӘРЕ

Кояш кызарып баеса, көн аяз була.

Кояш болытка баеса, кар явачак.

Кояш чыкканда, күк болытсыз булса, аяз көн көтелә.

Агач ботакларында кар аз икән, җәй көне урманда гөмбә дә, җиләк тә тапмассың.

Иртән соңгы әтәчләр белән тор да күккә кара: чәүкәләр кычкыра һәм төркем-төркем булып җиргә якын очалар икән — ерак юлга чыкма, буран булачак.

Ауга китәр алдыннан эткә кара: карга ятып ауный башласа, барма — көчле буранга эләгәсең.

Төньяк җиле исә башлады, ә болытлар юк — суыта.

Кичтән күктә йолдызлар күп булса, иртәгә салкын көн була.

Төнлә бәс төшсә, көндез кар яумаячак.

Мәче мич башына менсә, көн суыта.

Баш редактор —
В. Ф. Ихсанова.

Редколлегия членнары:
Н. З. Закирова
Ә. Ш. Мусина
Л. М. Мәһдиева
И. Г. Сункишева
С. Г. Сөләйманова
К. А. Шәмсетдинова
Г. Ш. Шәрәфетдинов
(баш редактор урынбасары)
И. Г. Юзиев
З. Н. Якупова
Р. А. Җиһаншина

Художник
И. Әхмәдиев.

Техник редактор
Э. Әдиатуллина.

Общественно-политический и литературно-художественный журнал «Азат хатын» («ОСВОБОЖДЕННАЯ ЖЕНЩИНА») на татарском языке.

Производствога бирелде 21/XI-1977 ел.
Басарга кул куелды 19/XII-1977 ел.
Тираж 364.000.
Заказ Б-431.
ПФ 07034.
Кәгазь форматы 60×90 1/8.
Күләме 3 басма табак.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ТЕЛЕФОННАР:
хатлар һәм авыл хуҗалыгы бүлекләре — 3-07-46;
промышленность, пропаганда, әдәбият һәм сәнгать бүлекләре — 3-07-42;
художник — 3-07-44;
фотокорреспондент — 3-07-67;
җаваплы секретарь — 3-57-69;
кабул итү бүлмәсе — 3-07-40;
баш редактор — 3-58-75.

БЕЗНЕҢ АДРЕС:
г. Казань — 420066,
ул. Декабристов, 2.
редакция журнала
«АЗАТ ХАТЫН».





ХУШЛАШУ СҮЗЕ

1977 елның 6 нчы ноябре көнне озак авырудан соң Заһидә Бурнашеваның (Гыйффәт туташ) йөрәге тибүдән туктады. Без хатын-кызларны элекке богаулардан коткаруда, аларны аң-белемгә һәм матур яңалык өчен көрәшкә тартуда иң актив коммунисткабызның берсен мәңгегә югалттык.

Заһидә Бурнашева 1895 елның 19 октябрендә Рязань өлкәсенең Әҗе авылында туган. Аның әти-әниләре, иске карашлы кешеләр булып, кызны элекке гореф-гадәтләр буенча тәрбияләргә омтылалар. Заһидә башлангыч белемне авыл мәктәбендә ала, укырга, язарга өйрәнә. Китаплар аны үз дөньяларына алып кереп китәләр. Укыган саен исә ул татар кызларының нинди аяныч язмышка хөкем ителгәнлекләрен тирәннәнрәк аңлый бара һәм Заһидә үзенең бөтен белемен азатлык өчен көрәшкә багышлый.

Әти-әни йортының тар кысаларын төю белән үк Заһидә туган авылыннан китәргә мәҗбүр була. Шул вакыттан башлап төрле газета-журналларда аның мәкаләләре, беренче шигырьләре басыла, «Гыйффәт туташ» псевдонимы белән шигырьләр җыентыгы чыга.

Заһидә Бурнашева Октябрь революциясен хуплап каршылый, совет властен ныгытышуда көчен кызганмый. 1918 елда аны коммунистлар сафына алалар. Заһидә Бурнашевага күбрәк Урта Азия шәһәр һәм авылларында эшләргә туры килә: Сәмәрканд, Ташкент, Кәттә Курган... Монда ул газета редакторы, хатын-кызлар өчен ачылган махсус курсларның мөдире, Үзбәк хатын-кызлар мәгариф институты укытучысы, Төркстан Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетында оештырылган мөселман хатын-кызлары секциясе җитәкчесе булып эшли.


Партия кушуы буенча аңа еш кына Мәскәүдәге зур киңәшмәләрдә катнашырга туры килә, даһи Ленинны күрү бәхетенә ирешә.

1921 елда Заһидә Бурнашева Мәскәүгә эшкә чакыртып алына, монда да ул хатын-кызларга яңа тормыш өчен көрәш юлларын аңлату буенча хезмәт итә. Бераздан аны кабат Урта Азиягә җибәрәләр.

Соңгы елларда ул Казанда яшәде. 1971 елда аның «Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан» исемле хезмәте басылып чыкты. Заһидә ханым «Азат хатын» журналы редакциясе белән өзлексез элемтәдә торды. Ул редакциянең актив хәбәрчесе, якын дусты һәм киңәшчесе иде.

Заһидә Бурнашеваның якты образы безнең күңелләрдә озак сакланыр.

МОДАЛАР













И. РОДИОНОВА эше.

Бәясе 20 тиен
Индекс 73002

ТЫШЛЫКТА:

БЕРЕНЧЕ БИТ. Казанның трамвай йөртү остасы — Әлфия Хәбибуллина.
М. ШАКИРҖАНОВ фотосы.

ДҮРТЕНЧЕ БИТ. Кышкы Казан.
С. ТОКАРЕВ фотосы.



